Вместе с тем Конституция Российской Федерации допускает ограничение прав и свобод человека и гражданина только федеральным законом и только в той мере, в какой это необходимо в целях защиты основ конституционного строя, нравственности, здоровья, прав и законных интересов других лиц, обеспечения обороны страны и безопасности государства (статья 55, часть 3).

Данным конституционным предписаниям корреспондирует положение статьи 1 Протокола № 1 к Конвенции о защите прав человека и основных свобод, предусматривающее, что каждое физическое или юридическое лицо имеет право на уважение своей собственности, никто не может быть лишен своего имущества кроме как в интересах общества и на условиях, предусмотренных законом и общими принципами международного права.

Согласно пункту 2 статьи 29 Всеобщей декларации прав человека при осуществлении своих прав и свобод каждый человек

должен подвергаться только таким ограничениям, какие установлены законом исключительно с целью обеспечения должного признания и уважения прав и свобод других и удовлетворения справедливых требований морали, общественного порядка и общего благосостояния в демократическом обществе. Аналогичные положения содержатся в пункте 3 статьи 12 Международного пакта о гражданских и политических правах и в статье 4 Международного пакта об экономических, социальных и культурных правах.

Конституция Республики Татарстан также предусматривает, что в Республике Татарстан признаются и защищаются равным образом частная, государственная, муниципальная и иные формы собственности (статья 18, часть первая); собственность неприкосновенна; ограничение прав собственника при владении, пользовании, распоряжении законно приобретенным имуществом не допускается, кроме случаев, предусмотренных федеральным законом (статья 19, часть первая); право частной собственности охраняется законом (статья 49); правовые акты органов местного самоуправления и должностных лиц местного самоуправления, противоречащие Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, федеральным законам и законам Республики Татарстан, подлежат отмене (статья 120).

Таким образом, пункты 1 и 2 Положения о движении по муниципальным автомобильным дорогам общего пользования, утвержденного решением Совета Альметьевского муниципального района от 5 августа 2008 года № 265, не соответствуют Конституции Республики Татарстан, ее статьям 18 (часть первая), 19 (часть первая), 27 (часть первая), 49 и 58 (часть вторая).

На основании изложенного, руководствуясь статьями 6, 63, частями первой и второй статьи 66, статьями 67, 68, 69, 71, 73 и 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**п о с т а н о в и л :**

1. Признать Правила благоустройства территории города Альметьевска Альметьевского муниципального района Республики Татарстан, утвержденные решением Альметьевского городского Совета Альметьевского муниципального района Республики Татарстан от 30 мая 2012 года № 63, и Положение о компенсации материального вреда, причиняемого тяжеловесными транспортными средствами автомобильным дорогам общего пользования, утвержденное постановлением Исполнительного комитета Альметьевского муниципального района от 26 февраля 2009 года № 691, в полном объеме не соответствующими Конституции Республики Татарстан, ее статье 24 (часть третья), поскольку они не были опубликованы официально для всеобщего сведения.

2. Признать пункты 1 и 2 Положения о движении по муниципальным автомобильным дорогам общего пользования, утвержденного решением Совета Альметьевского муниципального района

района от 5 августа 2008 года № 265, не соответствующими Конституции Республики Татарстан, ее статьям 18 (часть первая), 19 (часть первая), 27 (часть первая), 49 и 58 (часть вторая).

3. Прекратить производство по настоящему делу в части, касающейся проверки конституционности положения абзаца шестнадцатого пункта 6.7 Правил благоустройства территории города Альметьевска Альметьевского муниципального района Республики Татарстан, утвержденных решением Альметьевского городского Совета Альметьевского муниципального района Республики Татарстан от 30 мая 2012 года № 63, пунктов 1.1, 1.4, 1.5, 1.6 и таблицы № 2 Положения о компенсации материального вреда, причиняемого тяжеловесными транспортными средствами автомобильным дорогам общего пользования, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Альметьевского муниципального района от 26 февраля 2009 года № 691.

4. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

5. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 61-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**гражданин И.В. Авдеев шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең, Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2015 ел
19 март
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең, Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карап тикшерүгә гражданин И.В. Авдеевның шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларның аларны тулаем бастырып чыгару тәртибе буенча да, аерым нормаларның эчтәлеге буенча да Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә килеп туган билгесезлек эшне карап тикшерүгә нигез булды.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган органнар вәкилләренең — Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы

Советы аппаратының юридик бүлеге баш белгече Ә.Ә. Кыямова, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының Хокук идарәсе башлыгы Ф.Х. Шәйхуллова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган вәкилләрнең: Татарстан Республикасы Президентыннан — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең хокукый экспертиза бүлеге баш киңәшчесе Е.В. Кириллов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе башлыгы А.А. Ощепков, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан — Татарстан Республикасы Хөкүмәтеннән — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсе урынбасары Ю.Н. Олонова, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисеннән — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисеннән — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокурорыннан — Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Г.С. Галимов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлегенең әйдәүче консультанты К.А. Карпухин чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин И.В. Авдеев Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләре, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмә, Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаятьтән һәм аңа кушылып бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 6.7 пунктын бозып, махсус рөхсәттән-үткәрү документыннан башка авыр йөкле транспорт чарасын йөртүне гамәлгә ашыру рәвешендәге административ хокук

бозу кылган өчен гражданин И.В. Авдеев Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссиянең 2013 елның 21 августындагы карары белән Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 статьясындагы 1 өлеше нигезендә ике мең сум күләмендә штраф төрендәге административ җаваплылыкка тартылган.

Гражданин И.В. Авдеев үзен административ җаваплылыкка рәсми басылып чыкмаган норматив хокукый актлар нигезендә тартылган дип саный, чөнки аныңча Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару өчен рәсми матбугат басмасының — «Знамя труда» газетасының 2012 елның 6 июнендәге 43 нче санында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары гына, аның белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләреннән башка гына басылып чыккан. Ә Кагыйдәләре, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмә рәсми рәвештә бастырып чыгарылмаганнар.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин И.В. Авдеев Татарстан Республикасы Конституция судыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны, тулаем алганда, Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеше) туры килми дип тануны сорый, аның нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый.

Моннан тыш, гражданин И.В. Авдеев фикеренчә, күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацы, югарыда аталган Нигезләмәнең 1.1, 1.4, 1.5, 1.6 пунктлары һәм 2 нче таблицасы, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктлары үзләренең эчтәлеге буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә һәм аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацы нигезендә, аерым алганда, махсус рөхсәт-үткәрү документыннан башка авыр йөкле транспорт чараларын йөртү тыела.

Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган үзара бәйле 1 һәм 2 пунктларында авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары хуҗалары һәм алардан файдала-

нучылар мондый транспорт чаралары белән Әлмәт шәһәренең гомуми файдалану муниципаль автомобиль юлларына килгән зыянны каплыйлар; күрсәтелгән зыянны каплау максатында районның Башкарма комитеты раслаган рәвештәге махсус рөхсәтләр-үткәрү документлары кертелә дип билгеләнә.

Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең шикаять бирелә торган нормаларында авырлыгы 3,0 тонна һәм аннан авыррак булган йөк автотранспортыннан һәм автобуслардан түләү тиешле коэффициентлар кулланып алына дип карала: киметү өчен, әгәр йөкләнеш 10,0 тоннадан кимрәк булса, һәм арттыру өчен, әгәр йөкләнеш 10,0 тоннадан артыграк булса. 1 нче таблицада әлеге коэффициентлар күрсәтелә (1.1 пункт); әлеге Нигезләмә Әлмәт шәһәре эчендә йөри торган автомобиль транспорты хуҗаларыннан яисә алардан файдаланучылардан алына торган түләүнең күләмен, аны исәпләү һәм алу тәртибен билгели (1,4 пункт); Әлмәт шәһәре юл-урам челтәре буенча йөк машиналарының һәм транспорт чараларының хәрәкәте Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты вәкаләт биргән органнар тарафыннан бирелә торган махсус рөхсәтләр нигезендә генә гамәлгә ашырыла (1.5 пункт); шәһәрнең юл-урам челтәре буйлап транспорт йөртүгә рөхсәт транспорт йөрткән өчен тиешле түләүне кертү турында түләү документының күчермәсе күрсәтелгәндә генә бирелә дип билгели (1.6 пункт). Нигезләмәнең 2 нче таблицасында, транспорт чарасының йөк күтәрүчәнлегеннән чыгып, үткәрү документының (пропускның) хакы билгеләнә.

Гражданин И.В. Авдеев үзенең шикаятендә махсус рөхсәт һәм махсус үткәрү документы булмыйча, әгәр мондый документны алу мәҗбүри булса, авыр йөкләрне ташыган өчен административ җаваплылыкның Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.21.1 статьясындагы 1 өлешендә инде каралган булуын күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең дәгъва белдерелә торган нигезләмәсендә каралган хокукый җайга салу аның конституциячел хокукларын бозуга китерә, чөнки бер үк хокук бозуны кылган өчен ике административ җәза билгеләргә мөмкинлек бирә (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә).

Гражданин И.В. Авдеев билгеләп үткәнчә, Әлмәт шәһәре эчендә авыр йөкле транспорт чарасында хәрәкәт итү өчен махсус рөхсәт-үткәрү документы «Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмә хакында» Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары нигезендә кабул ителгән «Әлмәт муниципаль районында автотранспорт чаралары хәрәкәтен контрольдә тоту чаралары турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән кертелгән. Мөрәҗәгать итүче, шикаять бирелә торган нор-

матив нигезләмәләр белән билгеләнгән җайга салу Әлмәт муниципаль районы Советы һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре кысаларына сыймый, дип саный.

Аның фикеренчә, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган нормаларында авыр йөкле транспорт чаралары билгеләмәсендә төгәлсезлекләр бар: бер очракта транспорт чарасының йөк күтәрүчәнлегеннән, икенче очракта күчәрнең йөкләнешеннән чыгып билгеләнә, шуңа күрә бер үк төрле гамәл бер очракта хокук бозу булып саналырга, икенче очракта саналмаска мөмкин.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин И.В. Авдеев Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацын, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең 1.1, 1.4, 1.5, 1.6 пунктларын һәм 2 нче таблицасын, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар буенча Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары буенча һәм Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә танылa һәм гарантияләнә; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә, шөгыленең төренә һәм характерына, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; хосусый милек хокукы закон белән саклана; Татарстан Республикасы Конституциясендә төп хокукларны һәм ирекләрне санап чыгу кешенең һәм гражданның гомумтанылган башка хокукларын һәм ирекләрен кире кагу һәм киметү буларак аңлатылмаска тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Та-

тарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив-хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы законы яисә норматив хокукый акты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата шикаять бирү, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса, һәм, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт судта яисә башка органда карала башланган яисә карау төгәлләнгән конкрет эштә кулланылса яисә кулланылырга тиеш булса, мөмкин булып санала.

Гражданин И.В. Авдеевка карата Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссия чыгарган карарда Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турында нигезләмәгә һәм Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәгә сылтамалар юк. Ләкин махсус рөхсәт-үткәрү документыннан башка авыр йөкле транспорт чараларында йөргән өчен административ җаваплылыкны хокукый җайга салуда әлеге норматив хокукый актларның дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацы нигезләмәсе һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 статьясы белән тыгыз бәйләнештә тора, димәк, мөрәҗәгать итүченең административ эшендә турыдан-туры булмаса да кулланылган.

Шулай итеп, әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләре һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмә — аларны тулы күләмдә бастырып чыгару тәртибе буенча;

күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацының Әлмәт шәһәре эчендә авыр йөкле транспорт чарасында махсус рөхсәт-үткәрү документы буенча гына хәрәкәт итүне күздә

тота торган нигезләмәсе, югарыда аталган Нигезләмәнең 1.1, 1.4, 1.5, 1.6 пунктлары һәм 2 нче таблицасы, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктлары — эчтәлеге буенча.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының, шул исәптән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданнарның шикаятьләре буенча, кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен билгели.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый. Татарстан Республикасы Конституция суды бу конституциячел күрсәтмәне кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы һәм 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы карарлары).

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив хокукый актның гамәлдә булу яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы карар).

Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен һәм Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәне бастырып

чыгару тәртибе буенча затны административ җаваплылыкка тарту мәсьәләсе хәл ителгәнлектән һәм алар кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына, шул исәптән хосусый милекнең конституциячел хокукына кагылганга күрә, әлеге норматив хокукый актларның билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарылуы мәҗбүри булып тора.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның үзара бәйләнештәге 47 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре белән 44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты эчтәлегеннән күренгәнчә, җирле үзидарә органнарының кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла һәм федераль закон белән таратылуы чикләнә торган белешмәләре булмаган норматив хокукый актлары тиешле муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә тулы тексты белән басылып чыкса гына гомуми танышу өчен рәсми басылып чыккан дип танылырга мөмкин, уставта шул исәптән муниципаль хокукый актларның төрләре, кабул итү (нәшер итү), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш.

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре хокукый актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә кертү тәртибе «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 37 номерлы карары белән кабул ителгән Уставы белән җайга салына. Әлеге Уставның 72 статьясындагы 3, 5 һәм 9 өлешләре нигезендә кеше һәм гражданның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль хокукый актлар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә; шәһәр Советының норматив хокукый актлары 10 көн эчендә рәсми имзаланырга һәм бастырып чыгарылырга тиеш, моңа федераль закон белән таратылуы чикләнә торган белешмәләре булган муниципаль хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре керми; муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

хокукый акт текстын Шәһәр җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган басма массакүләм мәгълүмат органнарында, йә Шәһәр территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт тексты башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында билге ясарга кирәк;

— хокукый акт текстын гражданнарга үзәкләштерелгән тәртиптә, шул исәптән махсус матбугат басмасы рәвешендә җибәрү (тарату);

— хокукый акт текстын Шәһәр территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Күрсәтелгән стендларның саны һәм урнашу урыннары Шәһәр Советы тарафыннан раслана

һәм Шәһәр халкына муниципаль хокукый акт тексты белән тоткарлыксыз танышу мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш. Шәһәр Советы актларын рәсми бастырып чыгару чыганаклары статусына ия матбугат басмалары Шәһәр Советы карары белән билгеләнә.

«Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәне раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карар кабул ителгән вакытта Әлмәт муниципаль районы хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә кертү тәртибен җайга салган, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2005 елның 5 декабрендәге 17 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 258 номерлы карары редакциясендә), шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт район Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 116 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гамәлдәге уставы Әлмәт муниципаль районының хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) шундый ук алымнарын беркетә.

«Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару өчен рәсми матбугат басмалары турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2008 елның 31 октябрендәге 64 номерлы карары белән һәм «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару өчен рәсми матбугат басмалары турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 31 октябрендәге 270 номерлы карары белән Әлмәт шәһәрендә һәм Әлмәт муниципаль районында хокукый актларны бастырып чыгару өчен рәсми матбугат басмалары итеп «Знамя труда» һәм «Әлмәт таңнары», шулай ук соңрак «Альметьевский вестник» дип аталган «Яшьләр заманы» газетасы билгеләнгән.

Эш материалларыннан күренгәнчә, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары «Знамя труда» газетасының 2012 елның 6 июнендәге 43 нче санында, Кагыйдәләрнең Әлмәт муниципаль районының һәм Әлмәт шәһәренең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылуы күрсәтелеп, рәсми рәвештә басылып чыга. Шул ук интернет-сайтта Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмә дә урнаштырыла.

Шул рәвешле, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль

районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карарын аның белән расланган Кагыйдәләрнең Әлмәт муниципаль районының һәм Әлмәт шәһәренең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылуын күрсәтеп бастырып чыгару ул гражданнарга әлеге Кагыйдәләрнең эчтәлеге турында түгел, ә кабул ителүе турында гына мәгълүмат бирә. Күрсәтелгән Кагыйдәләрнең һәм Нигезләмәнең Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә таратыла торган басма массакүләм матбугат чараларына карамый торган әлеге интернет-сайтта урнаштыру аларны рәсми бастырып чыгаруның норматив беркетелгән рәвеше булып тормый һәм, димәк, аларның эчтәлеген гражданнар игътибарына җиткерү функциясен тулысынча үти алмый. Киресенчә булса, җирле үзидарә органнарыннан алар тарафыннан билгеләнгән күрсәтмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларны бастырып чыгару буенча закон таләпләре үтәлмәгәндә, алар әлеге күрсәтмәләрнең үтәлешен таләп итү мөмкин булыр иде, бу хокукый дәүләтнең конституциячел принципларына: хәбәрдарлыкка, хокук өстенлегенә, тигезлеккә һәм гаделлеккә туры килми.

Россия Федерациясе Конституция Суды да шундый ук алымны хуплый, үз карарларының берсендә ул Россия Федерациясенең вакытлыча кулланыла торган халыкара шартнамәләрен рәсми бастырып чыгармауны аларның эчтәлеген Россия Федерациясе гражданнарына һәм башка кызыксынучы затларга бүтән алымнар аша җиткерүне тиешенчә алмаштыра алмый дип күрсәтте, аерым алганда, мөрәҗәгать итүчегә карата Килешү текстын Таможня берлегенең рәсми интернет-сайтында урнаштыру алымы кулланылып, Россия Федерациясенең әлеге халыкара шартнамәсе төзелү турында кызыксынучы затларга мәгълүмат җибәрелсә дә, ул аның текстын тиешенчә рәсми бастырып чыгаруны алмаштыра алмый (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы карар). Россия Федерациясе төзегән халыкара шартнамәләрне аның хокукый системасының состав өлеше буларак карау Россия Федерациясенең конституциячел бурычы булудан чыгып (Россия Федерациясе Конституциясе, 15 статья, 4 өлеш) күрсәтелгән хокукый позиция универсаль булып тора һәм Россия Федерациясе хокукый системасының башка норматив актларына да кагыла.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләре, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 статьясына (өченче өлеш) тулы күләмдә туры килми, чөнки алар гомуми танышу өчен рәсми рәвештә бастырып чыгарылмаганнар.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды, мәгълүмат киңлегендәге объектив үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль хокукый актларны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда рәсми бастырып чыгару мөмкинлеген шик астына алмый. Күрсәтелгән ресурслар буларак, муниципаль берәмлекләрнең һәм аларның җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары да, рәсми хокукый мәгълүмат урнаштыру өчен каралган, мәсәлән, «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кебек интернет-порталлар да булырга мөмкин. Ләкин бастырып чыгаруның мондый алымы муниципаль берәмлекләрнең уставларында турыдан туры каралган очракта гына рәсми булып тора.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан күрсәтелгән Кагыйдәләрне һәм Нигезләмәне, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә бастырылып чыгарылмаганлыктан, Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 статьясына (өченче өлеш) тулы күләмдә туры килми дип тану әлеге норматив хокукый актлар үз көченә кермәгән буларак хокукый нәтиҗәләргә китерми һәм тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен нигез булып тора алмый дигәнне аңлата.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 һәм 101 статьялары мәгънәсе буенча норматив хокукый актлардагы нормалар эчтәлегенең конституциячеллеген тикшерү мөрәҗәгатьтә үз көченә кергән норматив нигезләмәләргә дәгъва белдерелгәндә генә мөмкин.

Димәк, гражданин И.В. Авдеевның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 30 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 6.7 пунктындагы уналтынчы абзацы нигезләмәсе, шулай ук Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 26 февралендәге 691 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән матди зыянны компенсацияләү турындагы нигезләмәнең 1.1, 1.4, 1.5, 1.6 пунктлары һәм 2 нче таблицасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаяте карала алмый, һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезендә әлеге эш күрсәтелгән өлешендә туктатылырга тиеш.

4. Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган 1 һәм 2 пунктларының хокукый нормалары юл эшчәнлеге мәсьәләләренә кагыла. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10 һәм 116 (беренче өлеш) статьялары нигезендә Татарстан Республикасында үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның хәл итүен тәэмин итә торган җирле

үзидарә танылa һәм гарантияләнә. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12 һәм 130 (1 өлеш) статьяларында да беркетелгән.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый (14 статьяның 1 өлешендәге 5 пункты). Шундый ук нигезләмәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктында да бар.

«Татарстан Республикасында яңа төзелгән җирлекләрдә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2005 елның 12 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җирлекнең җирле әһәмияттәге күрсәтелгән мәсьәләләре, шулай ук аларны хәл итү вәкаләтләре 2006 елның 1 гыйнварыннан шул исәптән Әлмәт муниципаль районына һәм аның җирле үзидарә органнарына тапшырылган (2 һәм 5 статьялар). Бу Закон 2006 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кереп, 2009 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан (9 статья).

Димәк, «Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмә хакында» 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карар кабул ителгән вакытта Әлмәт муниципаль районы Советы Россия Федерациясе законнары нигезендә Әлмәт шәһәре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар кабул итү вәкаләтләренә ия була.

4.1. Россия Федерациясендә автомобиль юлларыннан файдалануга, шул исәптән түләүле нигездә дә, һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

Әлеге Федераль законның 27 статьясындагы 1 өлеше, 28 статьясындагы 1 пункты һәм 29 статьясындагы 1 өлешенең 31 статья белән үзара бәйләнештәге нигезләмәләреннән аңлашылганча, автомобиль юлларыннан файдаланучылар гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап транспорт чараларын йөртүне һәм йөкләр ташуны иркле һәм түләүсез гамәлгә ашырырга хокуклы, моңа шушы ук Федераль законда күрсәтелгән очраклар һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә торган махсус рөхсәтләрдән башка автомобиль юллары

буйлап авыр йөкләр ташуны тыю очрагы да керми. Күрсәтелгән Федераль законның 31 статьясы нигезендә авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китергән зыянны каплау тәртибен һәм мондый зыянның күләмен билгеләү тәртибен урнаштыру Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләренә кертелгән (8 өлеш), ә әлеге статьяда каралган очракларда мондый махсус рөхсәтне бирү һәм авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыянның күләмен билгеләү, мондый транспорт чаралары җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткән очракта, җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән (6 өлеш һәм 9 өлешнең 3 пункты).

Шулай итеп, автомобиль юлларыннан файдаланучыларның транспорт чараларын түләүсез йөртүне гамәлгә ашыру хокукы федераль законнар нигезендә генә чикләнергә мөмкин. Авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларыннан килгән зыянны каплауны таләп итү шулай ук бары тик «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә генә һәм бу максатларда әлеге Федераль закон белән каралган махсус рөхсәттән файдаланып кына мөмкин.

Шул рәвешчә, күрсәтелгән зыянны каплау һәм, димәк, мондый транспорт чарасында йөрүгә махсус рөхсәт алу нигезләре федераль дәрәҗәдә билгеләнгән. Мәсәлән, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясындагы 3 өлешенең 2 пункты нигезендә авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт алу өчен әлеге транспорт чарасы хуҗасының мондый транспорт чарасыннан килгән зыянны каплавы таләп ителә.

Әлмәт шәһәренең гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплау бурычы Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 5 августындагы 265 номерлы карары белән расланган мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган Гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү турындагы нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларында каралган. Бу бурыч әлеге транспорт чараларының хуҗаларына да, алардан файдаланучыларга да йөкләнгән, ягъни дәгъва белдерелә торган нормалар сүзмә-сүз аңлашыла торган эчтәлеге буенча күрсәтелгән зыянны каплауны таләп итәргә, шулай ук әлеге таләпне үтәмәгән өчен шул исәптән транспорт хуҗасы белән төзелгән хезмәт шартнамәсе (хезмәт контракты) яисә граждани-хокукый шартнамә нигезендә үзенең хезмәт (эш, вазыйфаи) бурычларын үтәү йөзеннән авыр йөкле транспорт чарасы белән идарә итүче затларны административ җаваплылыкка тартырга мөмкинлек бирә.

Моннан тыш, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә Әлмәт

шәһәренең гомуми файдалану муниципаль автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплау максатында район Башкарма комитеты тарафыннан расланган рәвештәге махсус рөхсәтләр-үткәрү документлары кертелә дип каралган.

Ләкин дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны кабул иткән вакытка Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы тарафыннан 1996 елның 27 маенда расланган Россия Федерациясе юллары буйлап автомобиль транспортында эре габаритлы һәм авыр йөкләр ташу инструкциясе (Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2004 елның 22 гыйнварындагы 8 номерлы боерыгы редакциясендә) федераль законнарга каршы килмәгән өлешендә кулланылырга тиеш була, аның нигезендә юллар буйлап авыр йөкләр ташу әлеге Инструкциянең 2 нче кушымтасында китерелгән рәвеш буенча бирелә торган махсус рөхсәтләр буенча гына гамәлгә ашырылган (1.4 пункт).

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2012 елның 24 июлендәге 258 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль юллары буйлап авыр йөк һәм эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасына хәрәкәт итү өчен махсус рөхсәт алуның гамәлдәге тәртибе нигезендә махсус рөхсәт автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хуҗасына яисә аның вәкиленә махсус рөхсәт әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы үрнәк буенча бирелә (3 пункт).

Димәк, Әлмәт муниципаль районы Советы, күрсәтелгән транспорт чаралары хуҗаларыннан һәм алардан файдаланучылардан зыян каплатуны күздә тотып һәм әлеге максатлар өчен район Башкарма комитеты тарафыннан расланган рәвештәге махсус рөхсәтләр-үткәрү документлары кертеп, Әлмәт шәһәренең гомуми файдалану автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплау исәбеннән «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгәннән үзгә түләү алуга юл куйган.

Дәгъва белдерелә торган нормалар нигезендә зыянны каплау турында федераль законнарда каралганнан үзгә таләп кертелү авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларын махсус рөхсәт-үткәрү документы булмыйча йөртүне тыю белән дә раслана, ул башта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Әлмәт районы Советының 2008 елның 5 августындагы 261 номерлы карары белән билгеләнгән була, ә аны үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 статьясы нигезендә административ җаваплылык каралган.

Соңрак Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органна-

ры белән «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган, Әлмәт шәһәре җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплауны тәэмин итә торган, хокукый җайга салу да билгеләнә. Шулай итеп, «Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдалану автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китергән зыян күләмен билгеләү турында» 2011 елның 24 июнендәге 2482 номерлы карары белән Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 16 ноябрендәге 934 номерлы карары белән расланган Авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплау кагыйдәләренең 5 пункты белән билгеләнгән күрсәткечләрне арттырганда мондый зыянның күләм күрсәткечләрен раслады. Авыр һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары Әлмәт шәһәре автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү өчен махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр стандарты һәм аларны күрсәтү тәртибе Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 29 июнендәге 2609 номерлы карары белән расланган Административ регламент белән билгеләнә, ә ул үз көчен югалтканнан соң, тиешле административ регламентлар белән җайга салына. Әлмәт шәһәре автомобиль юллары буйлап әлеге махсус рөхсәттән башка авыр йөкләр ташу Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.21.1 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 31 октябрендәге 3772 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районының муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестрыннан күренгәнчә, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган махсус рөхсәт «Шәһәр автомобиль юллары идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан, ә гамәлгә кертү мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган Нигезләмә белән билгеләнгән махсус рөхсәт «Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан бирелә (16 һәм 50 пунктлар).

Шулай итеп, Әлмәт шәһәренең гомуми файдалану автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыянны каплау максатларында күрсәтелгән транспорт чаралары хуҗаларыннан ике тапкыр түләү алына.

4.2. Дәгъва белдерелә торган нормалар белән каралган түләү даими һәм мәҗбүри характерда, чөнки авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары белән китерелгән зыян-

**гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимов шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2015 ел
23 апрель
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимовның шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья А.А. Хамматова мәгълүматын, якларның — гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимовның, мөрәҗәгать итүчеләрнең вәкилләре Б.В. Королев, А.В. Земляной, Ю.А. Королева, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкилләренең — Татарстан Республикасы Дәүләт Советының законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе Ш.Ш. Яһудинның, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хокук бүлегенең өлкән юрисконсульты Р.Ф. Исмәгыйлевнең, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты хокук идарәсе башлыгының беренче урынбасары А.Н. Рыбушкинның, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгечне — Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары Р.И. Заһидуллинның аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган вәкилләрнең: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Респуб-

ликасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проекты эше бүлеге баш киңәшчесе Е.Е. Шехматованың, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе башлыгы А.А. Ощепковның, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцовның, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Д.Н. Горшуновның, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликовның, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Г.С. Галимовның, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинованың чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимовтан «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пункты белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата мөрәҗәгать алынды.

Дәгъва белдерелә торган норма нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән гавами чаралар уздыру яшәешне тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә комачаулык тудырса, һәм «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллык органнары, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре били торган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан урыннарда җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр уздыру тыела.

Мөрәҗәгатьтән һәм аңа кушылып бирелгән документларның

күчермәләреннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүчеләр әгъза булып торучы «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге Республика комитетыннан һәм Казан шәһәр комитетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры (алга таба — Г. Камал исемендәге театр) алдындагы мәйданда 2014 елның 1 маенда митинг, Г. Камал исемендәге театрдан Пушкин урамы буенча Ирек мәйданындагы В.И. Ленин һәйкәленә кадәр демонстрация һәм урам йөрешләре, Ирек мәйданында В.И. Ленин һәйкәле янында митинг үткәрү турында хәбәрнамә алынды. Дәгъва белдерелә торган нормага таянып, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гавами чараны оештыручы гражданин Х.Г. Миргалимовка хәбәрнамәдә күрсәтелгән маршрут буенча демонстрация һәм урам йөрешләре үткәрүне, Г. Камал исемендәге театр янындагы мәйданда митинг үткәрүне һәм митинг үткәрмичә Ирек мәйданында В.И. Ленин һәйкәленә чәчәк салуны гына килештереп, хәбәрнамәдә күрсәтелгән маршрут буенча демонстрация һәм урам йөрешләре үткәрүне килештерүдән баш тарткан. Бу гавами чарада катнашучылар, алар арасында гражданин А.В. Прокофьев та булган, Ирек мәйданына кадәр тротуарлар буенча, юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәп һәм күрсәтмә мәгълүмат атрибутикасыннан башка гына узарга тиеш булалар.

Г. Камал исемендәге театрдан Пушкин урамы буенча Ирек мәйданындагы В.И. Ленин һәйкәленә кадәр Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе символикасы белән флаг җилфердәтеп Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты белән килешенмәгән урам йөрешләре уздырган өчен гражданнар А.В. Прокофьевка һәм Х.Г. Миргалимовка карата административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелә. Татарстан Республикасы Югары судының 2014 елның 3 сентябрендәге карары белән үзгәрешсез калдырылган Казан шәһәре Вахитов район судының 2014 елның 31 июлендәге карары белән гражданин А.В. Прокофьев, гавами чарада катнашучы буларак, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.2 статьясындагы 5 өлеше нигезендә урам йөрешләре үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозган өчен 10 000 сум күләмендә административ штраф рәвешендәге административ җаваплылыкка тартылган. Татарстан Республикасы Югары судының 2014 елның 3 сентябрендәге карары белән үзгәрешсез калдырылган Казан шәһәре Вахитов район судының 2014 елның 31 июлендәге карары белән гражданин Х.Г. Миргалимов гавами чараны оештыручы буларак, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урам йөрешләрен оештыруның билгеләнгән тәртибен бозган өчен 10 000 сум күләмендә административ штраф рәвешендәге административ җаваплылыкка тартылган.

Татарстан Республикасы Югары судының 2014 елның 28 ноябрендәге карарлары белән Казан шәһәре Вахитов район судының 2014 елның 31 июлендәге карарлары һәм Татарстан Рес-

публикасы Югары судының 2014 елның 3 сентябрендәге карарлары юкка чыгарылган һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең эшләре Казан шәһәре Вахитов район судына яңадан карауга кайтарылган, 2015 елның 10 февралендәге карарлар белән гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимов югарыда аталган административ хокук бозуларны кылуда гаепле булып танылган.

Мөрәҗәгать итүчеләр фикере буенча, республика закон чыгаручысы, дәгъва белдерелә торган нигезләмәне кабул итеп, үзенә «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон белән бирелгән вәкаләтләрне арттырып җибәргән. Алар раславынча, шикаять бирелә торган нормада күрсәтелгән бинalardan һәм корылмалардан 50 метрдан якын урнашкан урыннарда гавами чаралар үткәрүне тыю аларны Татарстан Республикасының эре шәһәрләре үзәгендә үткәрүне тулысынча юкка чыгара. Аерым алганда, урам йөрешләре һәм демонстрацияләр үткәргәндә карала торган закон нигезләмәсендә санап кителгән биналарның һәм корылмаларның теләсә кайсысы теге яисә бу дәвамлы маршрут юлында очрый. Гражданнар А.В. Прокофьев һәм Х.Г. Миргалимов күрсәтелгән хокукый җайга салу аларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 43 статьясына каршы килә дип саныйлар, аның нигезендә Татарстан Республикасында гражданнар закон нигезенә тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлаулар уздырырга хокуклы.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды эш буенча карарны карала торган актның сүзгә-сүз мәгънәсендә, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив-хокукый актлар системасында аның урыныннан чыгып кабул итә.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пункты әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора, аның нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән гавами чаралар уздыру яшәешне тәэмин итү, транспорт йә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә комачаулык тудырса, һәм «Җыелышлар,

митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллык органнары, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре били торган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан урыннарда җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр уздыру тыела.

2. Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен, җәмәгать иминлеген тәэмин итү Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында тора (72 статья, 1 өлешнең «б» пункты). Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясе, 76 статья, 2 һәм 5 өлешләр).

Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрүне хокукый җайга салу «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге Федераль законда каралган очракларда җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрү шартларын тәэмин итүгә кагылышлы норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте чыгара, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары кабул итә һәм чыгара (1 статьяның 1 өлеше).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 2 пункты нигезендә закон чыгарып җайга салу, шул исәптән Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча, Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы мәсьәләләрне Россия Федерациясе Конституциясе белән билгеләнгән бүлешүдән чыгып эш иткән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 29 (3 өлеш) һәм 43 статьялары белән үзара бәйләнештә 75 статьясы (2 пункт) белән үзенә караган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 43 статьясы белән закон нигезендә тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре

һәм пикетлаулар уздырырга беркетелгән хокук гражданнар шәхси, сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни хокукларның һәм ирекләрнең бөтен тулылыгына ия булган, идеологик күптөрлелекне таный торган демократик хокукый дәүләттәге кебек Татарстан Республикасында шәхеснең хокукый статусын тәшкил итүче төп нигезләрнең берсе булып тора (1 статья, беренче өлеш; 12 статья, беренче өлеш; 30 статья). Тыныч җыелышлар ирегенә хокукны гарантияләүче шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 31 статьясында билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 59 статьясы нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска, дәүләт һәм җәмәгать иминлегенә, җәмәгать тәртибенә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына зыян китермәскә тиеш. Шуның белән бергә Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясында (3 өлеше) кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре федераль закон белән конституциячел төзелеш нигезләрен, башка затларның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, илнең оборонасын һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү максатларында кирәк булган кадәр генә чикләнергә мөмкин дип билгеләнә.

«Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон, гавами чара үткәрүгә конституциячел хокукны гамәлгә ашыру механизмын күздә тотып, 2 статьяның 1 пунктындагы һәм 8 статьяның 1 өлешендәге үзара бәйле нигезләмәләрдән аңлашылганча, гавами чараны — җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөреше һәм пикет рәвешендә йә әлеге рәвешләрнең төрле үрелешендә үткәрелә торган, аны үткәрү биналар һәм корылмалар җимерелү куркынычы тудырмаган яисә мондый чарада катнашучы затлар өчен дә, анда катнашмаучы затлар өчен дә башкача куркыныч янамаган очракта, бу чара максатлары өчен яраклы теләсә кайсы урында үткәрелергә мөмкин булган акция рәвешендә үткәрелә торган ачык, тыныч, һәркемгә рөхсәт ителә торган гавами чара дип билгеләде.

Россия Федерациясе Конституция Суды хокукый позициясе нигезендә гавами чаралар үткәрүгә Россия Федерациясе Конституциясе белән гарантияләнгән хокук абсолют булып тормый һәм зарурлык, пропорциональлек һәм туры килү принциплары һичшиксез үтәлгәндә, конституциячел әһәмиятле кыйммәтләрне яклау максатларында федераль закон белән чикләнергә мөмкин, кертелә торган чикләүләр әлеге конституциячел хокукның төп нигезен инкарь итмәскә һәм гражданнарга тыныч гавами акцияләр оештыру һәм үткәрү ярдәмендә үз карашларын, фикерләрен һәм таләпләрен ачыктан-ачык һәм ирекле белдерергә каршы килмәскә тиеш. Шулай итеп, мондый федераль закон тыныч җыелышлар үткәрү ирегенә хокукны тулысынча гамәлгә ашыру мөмкинлеген һәм бер үк вакытта — тиешле җәмәгать тәртибен һәм иминлекне, бер яктан, гавами чараларны оештыручылар һәм анда катнашучылар мәнфәгатьләре балансы нигезендә

гражданнарның сәламәтлеге һәм әхлагы өчен зыян китермичә һәм, икенче яктан, өченче затларның — барлык затларның (гавами чараларда катнашучыларның да, катнашмаучыларның да) хокукларын һәм ирекләрен, шул исәптән җәмәгать тәртибен һәм иминлекне, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуларны кисәтү һәм булдырмый калу буенча адекват чаралар кертү, шулай ук аларны боза торган яисә аларны бозу куркынычы тудыра торган гамәлләр өчен нәтиҗәле гавами-хокукый җаваплылык билгеләү юлы белән дәүләт яклавы зарурлыгыннан чыгып тәэмин итәргә тиеш (2012 елның 18 маендагы 12-П, 2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы карарлар; 2014 елның 22 апрелендәге 976-О номерлы Билгеләмә).

Мондый алым берничә халыкара-хокукый документта, шул исәптән Кеше хокукларының Гомуми декларациясендә (20 статьяның 1 пункты), шулай ук 21 статьясында закон нигезендә тыныч җыелышларга куела торган һәм демократик җәмгыятьтә дәүләт һәм җәмәгать иминлеген, иҗтимагый тәртипне, халыкның сәламәтлеген һәм әхлагын яисә башка затларның хокукларын һәм ирекләрен саклау өчен кирәк булган нигезле чикләүләр кертелүгә юл куя торган Граждани һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактта беркетелгән гомумтанылган принципларда һәм нормаларда күрсәтелә. Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Конвенциянең 11 статьясында тыныч җыелышлар ирегенә хокук тәртипсезлекләрне һәм җинаятьләрне булдырмау, башка затларның сәламәтлеген һәм әхлагын саклау яисә хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен милли иминлек һәм җәмәгать тәртибе мәнфәгатьләрендә закон белән каралган һәм демократик җәмгыятьтә кирәкле чикләүләрдән тыш, берninди чикләүләр куелмый торган буларак билгеләнә.

3.1. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законның (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 8 статьясындагы 1.1 һәм 2.1 өлешләре нигезләмәләре эчтәлегеннән аңлашылганча, гавами чаралар иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне күмәк тикшерү һәм җәмәгатьчелек фикерен чагылдыру өчен бердәй махсус каралган һәм яраклаштырылган, шулай ук, башлыча, иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар уңаеннан җәмәгатьчелек фикерен гавами чагылдыру буенча гражданнарның күпләп катнашуы өчен Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарына билгеләү вәкаләте йөкләнгән урыннарда (алга таба — махсус каралган урыннарда), шул исәптән махсус каралган урыннардан читтә үткәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе гражданнарының гавами чаралар үткәрүгә конституциячел хокукын гамәлгә ашыруын тәэмин итү «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге

91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 елның 24 июнендәге 436 номерлы карары белән муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре нигезендә махсус каралган урыннарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы билгели. Аерым алганда, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/84 номерлы боерыгы белән Казан шәһәре территориясендә махсус каралган урыннар расланды.

«Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законның (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 8 статьясындагы 2.1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы тарафыннан махсус каралган урыннар билгеләнгәннән соң гавами чаралар, кагыйдә буларак, шушы урыннарда үткәрелә. Шул рәвешле, гавами чараны махсус каралган урыннардан читтә үткәрү бары тик Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы белән килештерелгәннән соң гына рөхсәт ителә.

Гавами чара үткәрүне килештерү процедурасы күрсәтелгән Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешнең 2 пункты һәм 3 өлеше нигезләмәләре белән регламентлана, алардан чыгып Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы, әгәр хәбәрнамәдә әлеге Федераль законда яисә Россия Федерациясе субъекты законында гавами чараны үткәрү тыела торган урын күрсәтелгән булса, гавами чараны оештыручыга аны үткәрүне килештерүдән баш тарта; монда Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы гавами чараны үткәрү турында хәбәрнамә алганнан соң өч көн эчендә аны оештыручыга гавами чараны үткәрү урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турында нигезле тәкъдимне, шулай ук гавами чараны оештыручы тарафыннан аны үткәрү буенча хәбәрнамәдә күрсәтелгән үткәрү максатларының, рәвешләренең һәм башка шартларның югарыда аталган Федераль закон таләпләренә туры килмәүчелекне бетерү турында тәкъдимнәрне җиткерергә тиеш.

Шуңа бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр түбәндәгеләрне күрсәтте, «гавами чара үткәрүне гавами хакимият органы белән килештерү» — үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гавами хакимият органы үз теләге белән гавами чара үткәрүне тыя яисә аның максатларын, урынын, вакытын яисә рәвешен үзгәртә алуны күздә тотмый; ул бары тик аны үткәрү урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртүне тәкъдим итәргә хокуклы, өстәвенә мондый тәкъдим дәлилләнгән булырга һәм коммуналь яисә транспорт инфраструктурасының яшәеш өчен

мөһим объектларының нормаль һәм өзлексез эшләвен саклау зарурлыгына бәйле йә җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарның (гавами чараларда катнашучыларның да, аны үткәрү урынында оештыручы игълан иткән вакытта булырга мөмкин затларның) иминлеген тәэмин итү зарурлыгына, йә үзенең конституциячел бурычларын гамәлгә ашыру буенча тулы законлы билгеләнеше гавами хакимиятнең дискрециясен чикли торган башка шундый сәбәпләргә бәйле булырга тиеш. Гавами чараны оештыручыга адресланган аны үткәрүне килештерү таләбе — «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның үзара бәйле 2 статьясындагы 7 пункты, 7 статьясы, 10 статьясының 1 өлеше һәм 12 статьясының үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсе буенча — Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы, хәбәрнамә алгач, һәрхәлдә гавами чараны үткәрү урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турында үз тәкъдимнәрен оештыручыга җиткерү ярдәмендә аңа йогынты ясарга тиеш дигәнне аңлатмый. Киресенчә, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгара торган сәбәпләрнең юклыгына инанып («Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның 12 статьясындагы 3 өлеше), гавами хакимиятнең тиешле органы гавами чара оештыручы күрсәткән урында һәм планлаштырылган вакытта уздырылсын өчен үзеннән торган барлык чараларны барысын да күрергә һәм теләсә нинди сылтау белән гавами чараны оештыручының тәкъдимнәреннән чигенү зарурлыгын аклый алырлык сәбәпләр эзләмәскә тиеш. Шул рәвешле, гавами чара Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органының яисә җирле үзидарә органының раславын алганнан соң гына түгел, күрсәтелгән органнар аны үткәрү урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турындагы тәкъдимне законда билгеләнгән вакытта гавами чараны оештыручыга җиткермәгән очракта да килешенгән дип саналырга тиеш (2013 елның 14 феврале 4-П номерлы карары; 2009 елның 2 апрелендәге 484-О-П номерлы һәм 2014 елның 23 декабрендәге 2975-О номерлы билгеләмәләре).

Шулай итеп, гавами чараны оештыручы тарафыннан хәбәрнамәдә аны үткәрү закон белән тыелган урынны күрсәтү дә гавами чараны билгеләнгән урында үткәрүне һәм гавами хакимиятнең вәкаләтле органының гавами чараны үткәрү урынын үзгәртү турындагы тәкъдимен кертүне килештерүдән баш тарту өчен нигез булып тора. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) белән шундый урыннарга турыдан-туры куркыныч җитештерү объектлары янәшәсендәге һәм эксплуатацияләгәндә махсус куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен саклау таләп итеүә торган башка объектлар янәшәсендәге территорияләр; юлүткәргечләр, тимер юлы магистральләре һәм тимер юллар, нефть, газ һәм продуктүткәргечләр, югары вольтлы электр тапшырулары

линияләре буендагы полосалар; турыдан-туры Россия Федерациясе Президенты резиденцияләре, судлар били торган биналар, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәү учреждениеләре территорияләре һәм биналары янәшәсендәге территорияләр; шуңа вәкаләтле чик саклау органнарының махсус рөхсәте булмаган чик буе зонасы (8 статьяның 2 өлеше) керә. Моннан тыш, әлеге Федераль законның 8 статьясындагы 2.2 өлеше белән кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылык, хокук тәртибен, җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе субъекты законы белән шул исәптән гавами чаралар уздыру яшәешне тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яки транспорт яисә социаль инфраструктура объектларына керүенә комачаулык тудырса, җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр уздыру тыела торган урыннар өстәмә рәвештә билгеләнә.

«Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә), Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына җыелышларны, митингларны, урам йөрешләрен, демонстрацияләрне уздыру тыела торган урыннарны өстәмә билгеләү вәкаләтен биреп, аларны билгеләүнең төгәл, бер төрле алымнарын һәм гавами чаралар үткәрү тыела торган урыннарның пространство-территория характеристикаларын үз эченә алган критерийларны билгеләмәгән.

Закон чыгару өлкәсендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пунктында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән гавами чаралар уздыру яшәешне тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә тоткарлык тудырса, һәм «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) нигезендә җыелышларны, митингларны, урам йөрешләрен, демонстрацияләрне уздыру дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллык органнары, мәгариф, сәламәтлек сак-

лау учреждениеләре били торган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан урыннарда уздыру тыела дип караган.

Китерелгән хокукый җайга салу республика закон чыгаручысы тарафыннан үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, законлылыкны, хокук тәртибен, җәмәгать тәртибен тәэмин итү максатларыннан килеп чыга һәм гавами чараларда катнашучы затларның да, аларда катнашмаучы затларның да хокукларын һәм ирекләрен яклауга юнәлдерелгән. Дәгъва белдерелә торган нормада биналарның һәм корылмаларның күрсәтелгән исемлеген һәм гавами чараларны үткәрү өчен иң чик ара буларак 50 метр араны билгеләү мондый җайга салуны гамәлгә ашырганда федераль закон чыгаручы тарафыннан шактый киң ирек бирелүгә, шулай ук гамәлдәге региональ һәм җирле үзенчәлекләргә бәйле. Шул рәвешле, республика закон чыгаручысының үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне арттыруы турында мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлиле нигезсез.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган закон нигезләмәсе үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча киң затлар даирәсенең хокукларын һәм ирекләрен яклауга өстәмә гарантияләр билгеләүгә, гавами-хокукый һәм хосусый-хокукый мәнфәгатьләр нисбәтен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, кисәтү төсмерендәге чара булып тора һәм үзеннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый.

Шуның белән бергә, шикаять бирелә торган норма белән билгеләнгән әлеге нормада санап кителгән биналарга һәм корылмаларга 50 метрдан якынрак урнашкан урыннарда гавами чара үткәрүне тыю, карала торган Татарстан Республикасы законының 12 статьясының турыдан-туры эчтәлегеннән һәм системалы аңлатмасыннан аңлашылганча, бары тик кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән мондый чараны үткәрү закон белән билгеләнгән тискәре социаль күренешләргә китерергә мөмкин булса гына кулланыла. Дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмә әлеге Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы беренче абзацы белән уртак бәйләнештә тора, шуңа күрә гавами чараны оештыручының хәбәрнамәдә дәгъва белдерелә торган нормада каралган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан урынны күрсәтүе гавами хакимият органы өчен тыныч гавами чара үткәрүне килештерүдән баш тарту өчен бердәнбер һәм җитәрлек нигез булып тора алмый.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пункты үзенең эчтәлеге һәм конституциячел-

хокукый мәгънәсе буенча гамәлдәге хокукый җайга салу системасында дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллык органнары, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре били торган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан урыннарда үткәрелә торган гавами чараларны килештерүдән баш тарту бары тик кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән мондый чараны үткәрү аларның эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә тоткарлык тудырырлык, шулай ук дәгъва белдерелә торган статьяда билгеләнгән башка төрле зыян китерерлек булса гына рөхсәт ителә.

Шунын белән бергә «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законның (2012 елның 8 июнендәге 65-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 19 статьясы нигезендә гавами чараны килештерүдән баш тартуга карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирелергә мөмкин. Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә Россия Федерациясе Конституциясенең нәкъ менә мөстәкыйльлек, гаделлек, бәйсезлек, объектив һәм дөреслек принциплары нигезендә эш итүче суд хакимияте (Россия Федерациясе Конституциясенең 10, 118 һәм 120 статьялары) закон чыгаручыга конституциячел күрсәтмәләр кысаларында хокук кулланучыга күбесенчә җәмгыятьнең һәм аның сәяси оештырылган аерым ассоциацияләренең нисбәтен нәтиҗәле тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган бәяләү төшенчәләреннән файдалана торган закон нигезләмәләренә таянып бәхәсләрне хәл итү өчен каралган. Монда суд каравы гамәлдәге процессуаль законнар нигезендә сайлау хокуклары өлкәсендә бәхәсләрне карау өчен каралган максималь кыска срокта, ягъни планлаштырыла торган гавами чараны үткәрү датасына кадәр гамәлгә ашырылырга тиеш,— шулай булмаганда суд яклавы мәгънәсен югалтыр иде, ә бу Россия Федерациясе Конституциясенең 46 статьясы нигезендә мөмкин түгел (2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы карары; 2009 елның 2 апрелендәге 484-О-П номерлы Билгеләмәсе).

Татарстан Республикасы Конституция суды, шикаять бирелгән закон нигезләмәләрен куллану ачыкланган конституциячел хокукый мәгънә кысаларында, ягъни гавами чара үткәрү мөмкинлеге булмаган объектив билгеләнгән сәбәпләргә бәйле рәвештә генә гамәлгә ашырылырга тиеш һәм мондый чараны оештыручы белдергән максатларга һәм мәнфәгатьләргә нәтиҗәле ирешү өчен, гавами чарада катнашучыларның теге яисә бу гамәлләре аркасында килә торган зыяннарны тиешле дәрәҗәдә кисәтүгә шартлар тудыруга һәм законның тигезлек һәм өстенлек, гаделлек, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын хуплау принципларын бозуга китерүче хокук куллану эшчәнлегендә башбаштаклыкка юл куймаска тиеш дип билгеләп

үтә. Шикаять бирелә торган закон нигезләмәләрен башкача аңлату федераль закон чыгаручының «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның преамбуласыннан аңлашылганча, Россия Федерациясе гражданнарының тыныч, коралсыз җыелуга, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрергә конституциячел хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән аутентлык ихтыярына туры килмәс иде.

Мондый нәтиҗә тулысынча Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, анда гавами чараны килештергәндә гавами хакимиятнең вәкаләтле вәкилләре тарафыннан гавами чараны билдерелгән урында һәм (яисә) билдерелгән вакытта үткәрү теләге хупланмый гына түгел, конституциячел таныла торган кыйммәтләрне яклау зарурлыгына бәйле рәвештә аның мөмкин дә түгеллеген раслап, нигезле дәлилләр китерергә тиеш һәм гавами чараны оештыручыга аның максатларын гамәлгә ашыра торган, гавами чарада катнашучыларга үз таләпләрен ирекле куюны һәм чыгаруны, шул исәптән сәяси таләпләрне дә кертеп, вариантлар тәкъдим итәргә һәм аларны тиешле адресатларга җиткерергә тиеш дип күрсәтте. Гавами чараны оештыручылар, үз чиратында, мәнфәгатьләр балансы нигезендә тыныч җыелышлар ирегенә үзләренең конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен, ихтимал компромисска ирешү буенча акыллы һәм җитәрлек тырышлык чарасын күрергә тиеш. (2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы карары; 2014 елның 23 декабрендәге 2975-О номерлы, 2015 елның 29 гыйнварындагы 201 номерлы билгеләмәләре).

Гавами чараны килештерү процедурасын һәм якларның бурычларын бәяләгәндә мондый килештерүнең шундый ук алымын Кеше хокуклары буенча Европа Суды да хуплый, аның фикере буенча, хакимият гавами чараны тыймаган, киресенчә аны үткәрүнең альтернатив урынын тәкъдим иткән халәттә, әгәр ул шәһәр уртасында урнашса һәм күләмнәре буенча шактый зуррак булса, аны оештыручылар нинди дә булса ышандырырлык сәбәпләрдән башка үз чараларын башка урында үткәрү мөмкинлеген бирә торган хакимият тәкъдимен кире кага алмый (2012 елның 10 июлендәге «Берладир һәм Россиягә каршы башкалар» эше буенча карар).

Кеше хокуклары буенча Европа Суды үзенең прецедентлы практикасында дәүләт тыныч җыелышларга хокукны нигезсез чикләүләрне кулланудан тыелып торырга тиеш, аның әлеге хокукка тыкшынуы бары тик аны аклый торган ышанычлы һәм кире кагылмас дәлилләр булганда гына мөмкин дип күрсәтте (2005 елның 31 мартындагы «Төркиягә каршы Адали (Adaly)» эше буенча, 2005 елның 20 октябрендәге «"Уранио Токсо" (Ouranio Toxo) сәяси партиясе һәм Грециягә каршы башкалар» эше буенча һәм 2007 елның 26 июлендәге «Баранкевич Россиягә каршы» эше буенча карарлар).

Шулай итеп, гавами чараларны үткәрү урыннарын билгеләү

буенча бу рәвешле җайга салу тыныч җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр һәм урам йөрешләре ирегенә хокукының булуын инкарь итми, һәр конкрет очракта хокук кулланучыга гавами чарада катнашучы затларның, шулай ук анда катнашмаучы затларның мәнфәгатьләрен яклауны максималь тәэмин итә. Шуннан чыгып, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пункты кеше һәм гражданның конституциячел хокукын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең гавами чаралар үткәрүгә хокукын юкка чыгармый, киметми, башкача бозмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 43 статьясына каршы килми.

3.2. Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр һәм урам йөрешләре үткәрүгә гражданнарның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүнең хокукый җайга салынуын камилләштерүгә комачауламый. Демонстрацияләр һәм урам йөрешләре җыелышлардан һәм митинглардан аермалы буларак, анда катнашучыларның бер урында, шул исәптән дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллыклар, мәгариф, медицина оешмалары һәм гыйбадәтханә корылмалары биналары янәшәсендә янында озак вакыт булуын күздә тотмауны, шулай ук махсус каралган урыннар, демонстрацияләр һәм урам йөрешләре үткәрүгә исәпләнмәгән булуны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды республика закон чыгаручысы тарафыннан гавами чараларның аерым рәвешләрен үткәрү тәртибен җайга салуга, шул исәптән мондый чараларны үткәрү тыела торган урыннарны билгеләгәндә дифференциацияләнгән алымны кулланырга кирәк дип саный.

Бу Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә җавап бирер иде, анда берничә тапкыр күрсәтелгәнчә, гражданнар һәм аларның берләшмәләренә тыныч җыелышлар ирегенә хокукны тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен өстәмә шартлар тудыруга юнәлдерелгән махсус каралган урыннар алар территориясендә бары тик конкрет планлаштырылган маршрут буенча катнашучылар хәрәкәтенә бәйле булмаган аерым төрдәге гавами чаралар үткәрүгә генә исәпләнгән. Шул рәвешле, махсус каралган урыннарда гавами чаралар үткәрү мөмкинлеге үзеннән-үзе барлык очракларда да оештыручы күзлегеннән караганда гавами чараны башка, уңайлырак урында үткәрүгә тигез альтернатива буларак карала алмый (2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы һәм 2014 елның 13 маендагы 14-П номерлы карарлары).

Кеше хокуклары буенча Европа суды шулай ук җәмәгать урыныдагы теләсә нинди демонстрация теге яисә бу дәрәҗәдә, урам хәрәкәтенә комачаулауларны да кертеп, гадәти тормышны ко-

тылгысыз рәвештә боза, һәм Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында конвенциянең 11 статьясы белән гарантияләнгән җыелышлар иреге үзенең асылын югалтмасын өчен гавами хакимият тарафыннан тыныч җыелышларга карата аерым бер түземлек күрсәтү бик мөһим дип билгеләп үтте (2008 елның 23 октябрендәге «Сергей Кузнецов Россия Федерациясенә каршы» карары).

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясының беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 12 статьясындагы 3 пункты Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 62-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ИМЕНЕМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**по делу о проверке конституционности отдельных положений постановления руководителя Исполнительного комитета поселка городского типа Камское Устье Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан от 29 августа 2013 года № 10 «Об определении границ прилегающих к некоторым организациям и объектам территорий, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции» (в редакции от 15 сентября 2014 года) в связи с жалобой гражданина В.Ю. Синчугова**

23 июня 2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

руководствуясь статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3, частью первой и пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 68, 83, 100, 101 и 103 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»,

рассмотрел в открытом выездном судебном заседании дело о проверке конституционности отдельных положений постановления руководителя Исполнительного комитета поселка городского типа Камское Устье Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан от 29 августа 2013 года № 10 «Об определении границ прилегающих к некоторым организациям и объектам территорий, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции» (в редакции от 15 сентября 2014 года).

Поводом к рассмотрению дела явилась жалоба гражданина В.Ю. Синчугова. Основанием к рассмотрению дела явилась обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствует ли оспариваемый заявителем нормативный правовой акт Конституции Республики Татарстан.

Заслушав сообщение судьи-докладчика А.Р. Шакараева, объяснения сторон — гражданина В.Ю. Синчугова, представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт,— и.о. начальника юридического отдела аппарата Совета Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан Э.Э. Нургалиевой, выступления приглашенных в судебное заседание: представителя Президента Республики Татарстан — главного советника отдела по законопроектной работе Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан Р.В. Сидакова, представителя Государственного Совета Республики Татарстан — заведующего отделом гражданского законодательства Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан И.И. Фаттахова, представителя Кабинета Министров Республики Татарстан — Правительства Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан А.Б. Грев-

цова, представителя Председателя Верховного суда Республики Татарстан — судьи Верховного суда Республики Татарстан Э.С. Каминского, представителя Председателя Арбитражного суда Республики Татарстан — заместителя начальника отдела анализа и обобщения судебной практики Арбитражного суда Республики Татарстан А.Р. Бадретдиновой, представителя Прокурора Республики Татарстан — помощника Прокурора Республики Татарстан по взаимодействию с представительными (законодательными) и исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления А.Р. Валиахметова, представителя Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан — ведущего консультанта отдела по вопросам восстановления прав граждан аппарата Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан К.А. Карпухина, исследовав представленные документы и иные материалы, Конституционный суд Республики Татарстан

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступила жалоба гражданина В.Ю. Синчугова на нарушение его конституционных прав и свобод постановлением руководителя Исполнительного комитета поселка городского типа Камское Устье Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан от 29 августа 2013 года № 10 «Об определении границ прилегающих к некоторым организациям и объектам территорий, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции» (в редакции от 15 сентября 2014 года). Данным постановлением утверждены: Перечень территорий, прилегающих к некоторым организациям и объектам, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции (приложение № 1), Механизм определения границ прилегающих территорий, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции (приложение № 2), а также схемы границ прилегающих территорий для организаций и объектов, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции.

Как следует из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданин В.Ю. Синчугов полагает, что предусмотренный указанным постановлением порядок розничной продажи алкогольной продукции ограничивает его право на осуществление предпринимательской деятельности в этой сфере. В связи с этим он обращался в Камско-Устьинский районный суд Республики Татарстан с заявлением об оспаривании данного постановления, который решением от 26 июня 2014 года отказал в удовлетворении его требований.

В обоснование своей позиции заявитель указывает, что обозначенные в приложении № 1 к обжалуемому им постановлению размеры прилегающих территорий, на которых не допускается розничная продажа алкогольной продукции, варьируются от 20 до 100 метров. Тем самым, как он считает, оспариваемое постановление не устанавливает единого значения расстояния для

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясенең (Россия Федерациясе өчен ул 1998 елның 1 сентябреннән үз көченә керде) 4 статьясының 2 пункты нигезләмәсе туры килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары, закон тарафыннан билгеләнгән чикләр кысаларында, үз компетенцияләре өлкәсеннән чыкмаган һәм ниндидер башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә кайсы мәсьәлә буенча үз инициативасын тормышка ашыру өчен гамәлләр башкару ирегенә тулысынча ия.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды карала торган муниципаль норматив хокукый актның формасына игътибар итә. Дәгъва белдерелә торган карар Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе бланкында чыгарыла, ә, димәк, формасы буенча әлеге муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе карары булып тора. Моны аңа үзгәрешләр кертү турындагы актлар да раслый, аларның исемнәреннән күренгәнчә, үзгәрешләр нәкъ менә Башкарма комитет җитәкчесе карарына кертелгәннәр.

2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы (2009 елның 20 декабренә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) муниципаль берәмлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма комитет җитәкчесе) тарафыннан чыгарыла торган хокукый актлар җирле администрация башлыгы карарлары һәм боерыклары дип аталуын (6 статьяның 3 пункты) турыдан-туры күздә тоткан. Әмма «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның (2008 елның 25 декабрендәге 281-ФЗ номерлы редакциясендә) үтәлешен тәэмин итү йөзеннән кабул ителгән «“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 4 декабрендәге 62-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән яңа хокукый җайга салу кертелә, аның нигезендә җирле администрация башлыклары чыгарган хокукый актлар хәзерге вакытта җирле администрация карарлары һәм боерыклары дип атала.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган карар күрсәтелгән Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Законы гамәлгә кергәннән соң кабул ителгәнгә күрә, аны чыгарганда җирле

администрациянең хокукый актының закон тарафыннан билгеләнгән формасы бозыла. Шул ук вакытта аны үтәү мәҗбүри, чөнки ул закон таләпләренә нигезләнгән әһәмиятле процессуаль элемент булып тора. Моңа Россия Федерациясе Конституция Суды да күрсәтә, аның хокукый позициясе буенча федераль башкарма хакимият органнарының хокукый норматив актларының легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм игълан итү тәртибен үтәүне дә күздә тота; хокукый җайга салуның гамәлдәге системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект, кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне ала (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы карар). Күрсәтелгән хокукый позиция җирле үзидарә органнарының хокукый актларына карата да тулысынча кулланылышлы.

Әлеге эшне карау барышында Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан өйрәнелгән материаллардан күренгәнчә, җирле администрациянең норматив хокукый акты формасын бозу бердәнбер очрак кына булмыйча, ә Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе хокукый актларны чыгарганда урнашкан, тотрыклы практикага әверелә. Андый практика, закон чыгару күрсәтмәләренә туры килмәсә дә, элек хокук кулланучылар тарафыннан җирле администрациянең хокукый акты формасына карата алардан чыккан таләпләрне бозу буларак каралмый. Ул мөрәҗәгать итүче тарафыннан да дәгъваланмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъвалана торган карарның чыгарылу формасы буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә ярашлы түгел дип танылуы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесенең, шулай ук Татарстан Республикасындагы башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә башлыкларының (башкарма комитетлар җитәкчеләренең) элегрәк кабул ителгән башка хокукый актларының конституциячеллеген шик астына кую мөмкинлеген бирә алу фактын да игътибарга ала. Мондый нәтиҗә конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде, алар Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы буенча Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен яклау, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә 2013 елның 29 августындагы 10 номерлы «Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең чикләрен

билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе карарының (2014 елның 15 сентябрендәге редакциясендә) чыгарылу формасы буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә ярашлы булмавын танудан тыелып кала. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан ачыкланган Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма комитет җитәкчесе) тарафыннан чыгарылган хокукый актларның формасына карата законнар чыгаруда куелган таләбен үтәүнең конституциячел-хокукый мәгънәсе Татарстан Республикасындагы барлык муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары өчен мәҗбүри («Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 73 статьясы).

3. Татарстан Республикасы Конституциясендә Татарстан Республикасы икътисадының нигезен социаль базар хуҗалыгы тәшкил итүе, анда хуҗалык эшчәнлеге иреге һәм милек рәвешләренең күптөрлелеге, аларны хокукый яклауның тигез шартлары закон нигезендә тәэмин ителүе беркетелә (17 статья, беренче өлеш). Россия Федерациясе Конституциясендә шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый киңлекләрнең бердәмлеге һәм икътисадый эшчәнлек иреге тәэмин ителүе (8 статья, 1 өлеш); һәркемнең үз мөмкинлекләреннән һәм мөлкәтеннән эшмәкәрлек һәм закон белән тыелмаган башка төрле икътисадый эшчәнлек өчен ирекле файдалануга хокуклы булуы (34 статья, 1 өлеш) карала.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Суды берничә мәртәбә билгеләп үткәнчә, әлеге конституциячел хокук абсолют түгел, шуңа күрә федераль закон чыгаручы тарафыннан чикләнә ала, ул, эшмәкәрлек эшчәнлеген көйләү буенча үз вәкаләтләрен тормышка ашырып, аның башкарылу тәртибен һәм шартларын граждан хокуклары объектлары буларак теге яки бу продукция төрләрен җитештерүнең һәм аларның әйләнешенең спецификасыннан чыгып һәм Россия Федерациясе Конституциясе тарафыннан беркетелгән кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен бары тик федераль закон белән генә һәм бары тик анда беркетелгән кыйммәтләрне, шул исәптән әхлакны, сәламәтлекне, башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатында гына чикләү мөмкинлеген рөхсәт иткән критерийлар нигезендә билгели (2003 елның 12 ноябрендәге 17-П номерлы, 2013 елның 23 маендагы 11-П номерлы карарлары, 2004 елның 18 мартындагы 150-О номерлы һәм 2014 елның 23 декабрендәге 2942-О номерлы билгеләмәләре).

Россия Федерациясендә этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүнең һәм аларның әйләнешенең хокукый нигезләре «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында»гы Федераль закон тарафыннан билгеләнә.

Әлеге Федераль законның 1 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы буенча (2011 елның 18 июлендәге 218 номерлы Федераль закон редакциясендә) этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү әхлакны, сәламәтлекне, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясенең икътисадый мәнфәгатьләрен яклау, күрсәтелгән продукциянең куркынычсыз булуын, кулланучының аңа ихтыяҗын тәэмин итү максатларында, шулай ук җайга салына торган өлкәдәге законнарның, нормалар һәм кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатында башкарыла.

Алкоголь продукциясен ваклап сатуга аерым таләпләр әлеге Федераль законның 16 статьясында куела, аның 2 пунктыннан күренгәнчә, алкоголь продукциясен ваклап сату Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының Россия Федерациясе Хөкүмәте кабул иткән тәртиптә билгеләгән балалар, мәгариф, медицина оешмаларында, спорт объектларында, алар янәшәсендәге территорияләрдә; күпләп һәм ваклап сату базарларында, вокзалларда, аэропортларда, гражданнарның башка күпләп җыелу урыннарында һәм югары куркынычлык чыганаклары булган урыннарда, шулай ук шундый урыннар янәшәсендәге территорияләрдә; хәрби объектларда һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә рөхсәт ителми. Шул ук вакытта әлеге статьяның 4 пункты буенча янәшәдәге территорияләргә биналар, каралтылар һәм корылмаларның турыдан-туры янәшәсендә булган җир участоклары керә һәм аларның чикләре 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары куркынычлык чыганаклары булган урыннарны билгеләү турында һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең чикләрен билгеләү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең чикләрен билгеләү кагыйдәләрендәге тәртиптә җирле үзидарә органнары карарлары белән билгеләнәләр.

Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралганча, җирле үзидарә органнары, стационар сәүдә объектларында алкоголь продукциясен ваклап сатуны һәм җәмәгать туклану хезмәтен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны тыю өчен, оешмалар һәм (яки) объектлар янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең (алга таба — янәшәдәге территория) чикләрен төрлечә билгеләргә хокуклы. Күрсәтелгән пункт нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының Россия Федерациясе Хөкүмәте кабул иткән тәртиптә билгеләнгән балалар, мәгариф, медицина оешмалары,

спорт объектлары, күпләп һәм ваклап сату базарлары, вокзаллар, аэропортлар, гражданнарның башка күпләп җыелу урыннары һәм югары куркынычлык чыганаклары булган урыннар, шулай ук хәрби объектлардан җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган янәшәдәге территорияләрнең чикләренә кадәрге максималь ераклык күрсәткечe муниципаль берәмлектә һәр оешма һәм (яки) объект төре кысаларында күрсәтелгән ераклыкның минималь күрсәткеченнән 30 процентка күбрәк була алмый.

Дәгъва белдерелә торган Исемлектә алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләрнең чикләре билгеләнгән оешма һәм объектларның төрләре «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законының 16 статьясының 2 пунктында турыдан-туры каралган. Искә алынган Федераль законда һәм федераль законнарда гражданин В.Ю. Синчуговның шикаятендә күрсәтелгән инвалидларның реабилитацияләнү һәм пенсионерларның көндез калу үзәге, җәмәгать транспорты тукталышлары, шулай ук дини корылмалар янәшәсендәге территорияләрдә алкоголь продукциясен ваклап сатуны тыю гомумән күздә тотылмый. Моннан чыгып, андый объектларны күрсәтелгән Исемлеккә кертү, мөрәҗәгать итүче шуны сорый да, Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының җирле үзидарә органы вәкаләтләре чигеннән чыгачак. Башкасы, асылда, эшкуарлык эшчәнлеген башкару хокукын чикләүне аңлатыр иде, бу исә Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясының 3 өлеше нигезендә федераль закон чыгаручының махсус компетенциясенә карый.

Бәян ителгәннәрдән күренгәнчә, Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының җирле үзидарә органы, Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең исемлеген (дәгъва белдерелә торган карарның 1 нче кушымтасы) раслап, оешмаларның (объектларның) үзен дә, алар янәшәсендәге территорияләрнең зурлыгын да хаклы билгеләли. Шул ук вакытта күрсәтелгән территорияләрнең зурлыклары, нинди төрдәге оешма һәм объектлар янында булуларына карап, шул исәптән аларның социаль әһәмиятлелек дәрәҗәсен һәм тәңгәллеген сыйфатлый торган объектив бәйле критерийлар нигезендә, шулай ук бер оешма (объект) төре кысаларында янәшәдәге территорияләр ераклыгының минималь һәм максималь күрсәткечләр нисбәтенең мөмкин булган законлы чикләрен саклап, төрлечә бирелгән.

Мондый алым 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактның үтәлешен контрольдә тота торган Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану тәҗрибәсенә тәңгәл булып тора, аның буенча закон каршында тигез хокуклылыкка һәм берниндi дә дискриминациясез закон тарафыннан тигез яклауга хокук мөрәҗәгатьтәге теләсә кайсы аермалыклар һәм шартлар дискриминацияли дигәнне аңлатмый, шуңа күрә дәлилле һәм объектив критерийларга нигезләнгән

дифференциация Пактның 26 статьясының мәгънәсе буенча тыелган дискриминациягә тәңгәл түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы территориясендә кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең зурлыгын билгеләү тәртибе Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү механизмының 3 пунктында (дәгъва белдерелә торган карарның 2 нче кушымтасы) билгеләнгән. Күрсәтелгән пунктның эчтәлегеннән күренгәнчә (2014 елның 15 сентябрендәге редакциясендә), оешма һәм (яки) объекттан, керү урыныннан керү урынына яки янәшәдәге территорияләрнең (булган очракта) чигенә кадәрге ераклык иң кыска юл буенча (турыдан), ясалма һәм табигый киртәләрне исәпләмичә санала.

Әлеге хокукый җайга салу 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Кагыйдәләрнең 7 пунктындагы нигезләмәләргә таяна, алар буенча алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешма һәм (яки) объектлардан янәшәдәге территорияләрнең чикләренә кадәрге ераклыкны билгеләү ысулы җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә. Әлеге Кагыйдәләрнең 4 пункты буенча алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм объектлар янәшәсендәге территория аерымланган территорияне (булган очракта), ягъни алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бина (каралты, корылма) янәшәсендәге, чикләре киртә (ясалма объектлар) белән билгеләнгән территорияне (алга таба — аерымланган территория), шулай ук алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (каралты, корылма) яки аерымланган территория чикләренә тоташкан, җирлекнең һәм корылмаларның конкрет үзенчәлекләрен исәпкә алып билгеләнә торган территорияне (алга таба — өстәмә территория) үз эченә ала. Өстәмә территория, аерымланган территория булган очракта, шул ук Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә аерымланган территориягә килүчеләр өчен керү урыныннан стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керү урынына кадәр билгеләнә, ә аерымланган территория булмаган очракта — алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (каралты, корылма) килүчеләр өчен керү урыныннан стационар сәүдә объектына килүчеләр өчен керү урынына кадәр.

«Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында»гы Федераль законның да, күрсәтелгән Кагыйдәләрнең дә алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм (яки) объектлардан янәшәдәге территорияләрнең чикләренә кадәрге ераклыкны исәпләү ысулын яки методикасын сайлауда нинди дә булса чикләүләр куймауларын билгеләп үтәргә кирәк.

Моңа бәйле рәвештә алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган оешмалар һәм (яки) объектлар янәшәсендәге территориянең конкрет зурлыкларын билгеләү, шулай ук аны исәпләү ысулын яки методикасын сайлау җирле үзидарә органының махсус дискрециясенә карый һәм янәшәдәге территорияләрне билгеләгәндә җирлекнең һәм корылмаларның үзенчәлекләренә бәйле.

Дәгъва белдерелә торган норманың максатчан билгеләнеше булып, Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү механизмының эчтәлегеннән һәм мәгънәсеннән күренгәнчә, Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында шундый территорияләрнең зурлыгын билгеләүдә бертөрле алым куллануны тәэмин итү тора. Күрсәтелгән Механизмның 3 пунктындагы дәгъвалана торган норма федераль законнар таләпләре нигезендә билгеләнә һәм хокук куллану практикасында үзенең ирекле аңлатылу мөмкинлегенә юл куймый. Димәк, мөрәҗәгать итүченең дәгъвалана торган пунктның эчтәлегендә билгелелелек һәм ачыклык булмау турындагы дәлиле нигезсез.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, карала торган норматив нигезләмәләр, хокукый асылы буенча, әхлакны, сәламәтлекне, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәргә бурычлы билгеләнгән башкару тәртибен исәпкә алып, алкоголь продукциясен ваклап сату өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлегенә хокукны тормышка ашыруга юнәлдерелгән. Моңа бәйле рәвештә андый нигезләмәләр эшмәкәрлек эшчәнлеге ирегенең конституциячел гарантияләрен боза торган итеп карала алмый. Алар шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясы нигезендә гарантияләнгән тигезлек принцибын боза торган итеп тә карала алмый, чөнки алар, мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә каршы, алкоголь продукциясен ваклап сату белән шөгыльләнүче барлык эшмәкәрләргә кагыла.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының әлеге хокукый позициясенә тәңгәл килә: әйләнеш мөмкинлекләре чикле булган объектларга караган этил спирты, алкоголь һәм спирт продукциясе кебек үзенчәлекле продукцияне җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, Россия Федерациясенең икътисадый мәнфәгатьләрен яклау, кулланучыларның шул продукциягә ихтыяҗын тәэмин итү, аның сыйфатын күтәрү, шулай ук җайга салына торган өлкәдәге законнарның, нормалар һәм кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту кирәклегенә бәйле (2003 елның 12 ноябрендәге 17-П номерлы карар).

Шулай итеп, 2013 елның 29 августындагы 10 номерлы «Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе карары (2014 елның 15 сентябрендәге редакциясендә)

белән расланган Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең исемлеге (1 нче кушымта), шулай ук Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү механизмының 3 пункты (2 нче кушымта) эчтәлекләре буенча мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый һәм шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституциясенә, шул исәптән аның 17, 20, 22 статьяларына һәм 28 статьясына (беренче һәм икенче өлеше) каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясының беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясының беренче өлешендәге 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. 2013 елның 29 августындагы 10 номерлы «Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе карары (2014 елның 15 сентябрендәге редакциясендә) белән расланган Кайбер оешма һәм объектларның янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең исемлеге (1 нче кушымта), шулай ук Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү механизмының 3 пункты (2 нче кушымта) Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 63-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацами шестнадцатым и семнадцатым Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования»**

24 апреля
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.С. Рахматуллина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацами шестнадцатым и семнадцатым Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования». Оспариваемыми абзацами установлено, что в границах территорий объектов культурного наследия федерального значения, утверждаемых указанным постановлением, запрещается размещение объектов капитального строительства и их частей, а также проектирование, проведение землеустроительных работ, земляных, строительных, хозяйственных и иных работ, не связанных с сохранением объектов культурного наследия.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является собственником 1/2 доли земельного участка, расположенного в границах территории объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.», и 1/2 доли находящегося на данном земельном участке здания общественного туалета. С целью изменения вида разрешенного использования земельного участка в связи с реконструкцией указанного здания в объект общественного питания гражданка Г.С. Рахматуллина обратилась в Управление архитектуры и градостроительства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, а также в Исполнительный комитет муниципального об-

разования города Казани и в Министерство культуры Республики Татарстан.

Из содержания ответов вышеуказанных органов на ее обращения следует, что с учетом требований оспариваемых норм реконструкция здания общественного туалета, расположенного в границах объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.», возможна только в рамках работ по его сохранению на основании письменного задания и разрешения Министерства культуры Республики Татарстан. Письменное разрешение выдается после согласования указанным Министерством проектной документации, получившей положительное заключение государственной историко-культурной экспертизы.

Заявительница считает, что обжалуемые абзацы Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, регулируют правоотношения в границах территорий объектов культурного наследия не республиканского, а федерального значения и, следовательно, не должны распространяться на объект культурного наследия «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.». Кроме этого, она указывает, что в оспариваемых положениях не учтены интересы частных собственников, имеющих объекты, не являющиеся объектами культурного наследия, но размещенные при этом в границах территорий объектов культурного наследия.

На основании изложенного гражданка Г.С. Рахматуллина полагает, что обжалуемые положения нарушают права собственников, ущемляют их в выборе экономической деятельности, а также не признают и не защищают равным образом частную собственность по сравнению с муниципальной и государственной формами собственности. В связи с этим она просит признать абзацы шестнадцатый и семнадцатый Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования», не соответствующими статьям 18 (часть первая), 19 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 Конституции Республики Татарстан.

2. Отношения в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации регулирует Федеральный закон от 25 июня 2002 года № 73-ФЗ «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации». Гарантируя гражданам Российской Федерации сохранность объектов культурного наследия в интересах настоящего и будущего поколений, названный Федеральный закон установил особенности

проектирования и проведения землеустроительных, земляных, строительных, мелиоративных, хозяйственных и иных работ на территории объекта культурного наследия и в зонах охраны объекта культурного наследия. Так, согласно пункту 2 статьи 35 данного Федерального закона (в редакции, действовавшей до внесения изменений Федеральным законом от 22 октября 2014 года № 315-ФЗ) проектирование и проведение землеустроительных, земляных, строительных, мелиоративных, хозяйственных и иных работ на территории памятника или ансамбля запрещаются, за исключением работ по сохранению данного памятника или ансамбля и (или) их территорий, а также хозяйственной деятельности, не нарушающей целостности памятника или ансамбля и не создающей угрозы их повреждения, разрушения или уничтожения. Аналогичные по своему содержанию и правовому смыслу положения в настоящее время закреплены в подпункте 1 пункта 1 статьи 5.1 указанного Федерального закона.

Оспариваемые положения Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования», по существу, воспроизводят требования и нормы Федерального закона «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации». Исходя из этого проверка конституционности обжалуемых гражданкой Г.С. Рахматуллиной абзацев фактически означала бы оценку указанных норм федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

Оспариваемые заявительницей нормы сами по себе не содержат неопределенности в вопросе о соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение заявительницы не является допустимым.

Кроме того, Конституционный суд Республики Татарстан считает, что Кабинету Министров Республики Татарстан необходимо уточнить категорию историко-культурного значения объектов культурного наследия в оспариваемом заявительницей абзаце шестнадцатом Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, исходя из наименования и фактического содержания постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и

режима их использования». Такое регулирование в полной мере будет отвечать требованию правовой определенности, точности, ясности и недвусмысленности.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацами шестнадцатым и семнадцатым Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. В соответствии с подпунктом 2 пункта 1 статьи 333.40 Налогового кодекса Российской Федерации государственная пошлина, уплаченная гражданкой Г.С. Рахматуллиной, подлежит возврату полностью.

3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

4. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.С. Рахматуллиной и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

5. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 2-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының уналтынчы һәм унҗиденче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
24 апрель
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә суд утырышында гражданка Г.С. Рәхмәтуллинаның шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының уналтынчы һәм унҗиденче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъва белдерелә торган абзацлар белән күрсәтелгән карар нигезендә раслана торган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук җир төзелеше эшләре, мәдәни мирас объектларын саклауга бәйле булмаган җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау, башкару тыела.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче «“Черное озеро”, шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең 1/2 өлешенең һәм әлеге җир кишәрлегендә урнашкан җәмәгать бәдрәфе бинасының 1/2 өлешенең милекчесе булып тора. Күрсәтелгән бинаның җәмәгать туклануы объекты итеп үзгәртелүенә бәйле рәвештә, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү

максатында гражданка Г.С. Рәхмәтуллина Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать итте.

Югарыда күрсәтелгән органнарның әлеге мөрәҗәгатькә бирелгән җаваплары эчтәлегеннән аңлашылганча, «“Черное озеро”, шәһәр бакчасы XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты чикләрендә урнашкан җәмәгать бәдрәфе бинасын реконструкцияләү дәгъва белдерелә торган нормалардагы таләпләрне исәпкә алып, бары тик аны саклау буенча башкарыла торган эшләр кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының язма биреме һәм рөхсәте нигезендә генә мөмкин. Язма рөхсәт дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документациясен күрсәтелгән министрлык белән килештергәннән соң бирелә.

Мөрәжәгать итүче Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни-мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының шикаять бирелә торган абзацлары мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә республика әһәмиятендәге хокук мөнәсәбәтләрен түгел, федераль әһәмияттәге хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала һәм, димәк, «“Черное озеро”, шәһәр бакчасы XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектына кагылырга тиеш түгел дип саный. Моннан тыш, мөрәжәгать итүче күрсәткәнчә, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә мәдәни мирас объектлары булып тормаган, ләкин шул ук вакытта мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә урнашкан объектларга ия булган хосусый милекчеләрнең мәнфәгатьләре исәпкә алынмаган.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданка Г.С. Рәхмәтуллина фикеренчә, шикаять бирелә торган нигезләмәләр милекчеләрнең хокукларын боза, аларның икътисадый эшчәнлек белән шөгыльләнүенә комачаулый, шулай ук муниципаль милек һәм дәүләт милке белән чагыштырганда хосусый милекне бертигез дәрәҗәдә танымый һәм якламый. Шуңа бәйле рәвештә, мөрәжәгать итүче «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының уналтынчы һәм унҗиденче абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (беренче өлеш), 19 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләр

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына. Россия Федерациясе гражданнарына хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә, мәдәни мирас объектларының сакланышын гарантияләп, югарыда аталган Федераль закон мәдәни мирас объекты территориясендә һәм мәдәни мирас объектын саклау зоналарында җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм башкару үзенчәлекләрен билгеләде. Мәсәлән, әлеге Федераль законның (2014 елның 22 октябрендәге 315-ФЗ номерлы Федераль закон белән үзгәрешләр кертелгәнчегә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 35 статьясындагы 2 пункты нигезендә һәйкәл яисә ансамбль территориясендә җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм башкару тыела, моңа әлеге һәйкәл яисә ансамбльне һәм (яисә) аларның территорияләрен саклау, шулай ук һәйкәл яисә ансамбльнең бөтенлеген бозмый торган һәм аларны зарарлау, җимерү һәм юкка чыгару куркынычы тудырмый торган хуҗалык эшчәнлеге керми. Үзенең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча шундый ук нигезләмәләр хәзерге вакытта күрсәтелгән Федераль законның 5.1 статьясының 1 пунктындагы 1 пунктчасында билгеләнгән.

«Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре, асылда, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль закон таләпләрен һәм нормаларын кабатлыйлар. Моннан чыгып, гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаять бирә торган абзацларның конституциячеллеген тикшерү фактта күрсәтелгән Федераль закон нормаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, ә бу Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган нормаларның үзләрендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясының беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате карала алмый.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституция суды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерелә торган уналтынчы абзацын, «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары исеменнән һәм факттагы эчтәлегеннән чыгып, мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен ачыкларга кирәк дип саный. Бу рәвешле җайга салу хокукый билгеләнеш, төгәллек, ачыклык һәм мәгънә берлеге таләпләренә тулысынча җавап бирәчәк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче, икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына һәм 101 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының уналтынчы һәм унҗиденче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый.
2. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.40 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә гражданка Г.С. Рәхмәтуллина түләгән дәүләт пошлинасы тулысынча кире кайтарылырга тиеш.
3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
4. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.С. Рәхмәтуллинага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.
5. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 2-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Т.Н. Рудницкой на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан»**

18 мая 2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Т.Н. Рудницкой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Т.Н. Рудницкая с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан».

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что решением Ново-Савиновского районного суда города Казани от 17 октября 2011 года был установлен и определен порядок общения гражданки Т.Н. Рудницкой с несовершеннолетней внучкой по месту жительства заявительницы. Кассационным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан от 14 ноября 2011 года указанное решение было оставлено без изменения. Определением Ново-Савиновского районного суда города Казани от 20 ноября 2014 года были изменены порядок и способ исполнения решения Ново-Савиновского районного суда города Казани от 17 октября 2011 года и определено, что общение бабушки — гражданки Т.Н. Рудницкой с внучкой должно проходить в квартире по месту жительства ребенка.

Как указывает заявительница, требования судебного пристава-исполнителя к родителям ребенка об исполнении решения суда в установленном порядке не выполняются и она не может общаться со своей несовершеннолетней внучкой. В связи с этим гражданка Т.Н. Рудницкая обращалась с заявлением о содействии в разрешении сложившейся ситуации в различные инстанции, в том числе в отдел опеки и попечительства Авиастроительного и Ново-Савиновского районов города Казани. Однако, как следует из ответов на ее обращения, осуществление функций по принудительному исполнению судебных актов согласно законодательству не относится к их компетенции.

Оспариваемыми нормами статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан установлено, что защита прав и законных интересов ребенка осуществляется родителями (лицами, их за-

меняющими), а в случаях, предусмотренных Семейным кодексом Российской Федерации,— органом опеки и попечительства, прокурором и судом (часть 2); должностные лица организаций и иные граждане, которым станет известно об угрозе жизни или здоровью ребенка, о нарушении его прав и законных интересов, обязаны сообщить об этом в орган опеки и попечительства по месту фактического нахождения ребенка; при получении таких сведений орган опеки и попечительства обязан принять необходимые меры по защите прав и законных интересов ребенка (часть 6).

Обжалуемой статьей 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» определены функции органов опеки и попечительства.

Гражданка Т.Н. Рудницкая отмечает, что установленное оспариваемыми положениями регулирование приводит к нарушению как ее законных прав и интересов, так и ее внучки, поскольку не устанавливает механизм согласованного взаимодействия органов опеки и попечительства и службы судебных приставов, направленного на обеспечение исполнения судебных актов, вынесенных в отношении несовершеннолетних лиц. Заявительница также считает неправомерным отсутствие у органов опеки и попечительства функции по осуществлению принудительного исполнения судебных актов, вынесенных в отношении несовершеннолетних лиц, так как, по ее мнению, указанный орган, исходя из своего целевого предназначения должен содействовать исполнению родителями ребенка судебного решения и способствовать реализации положений статьи 58 Семейного кодекса Республики Татарстан, предусматривающих право бабушки на общение с внучкой.

Таким образом, заявительница указывает, что части 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан и статья 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» нарушают ее конституционные права и просит признать их не соответствующими статьям 38 (части первая, третья и четвертая), 40 (часть первая), 60 Конституции Республики Татарстан.

2. Семейное законодательство в силу пункта 2 статьи 3 Семейного кодекса Российской Федерации состоит из данного Кодекса и принимаемых в соответствии с ним других федеральных законов, а также законов субъектов Российской Федерации, при этом нормы семейного права, содержащиеся в законах субъектов Российской Федерации, должны соответствовать указанному Кодексу.

Согласно статье 56 Семейного кодекса Российской Федерации защита прав и законных интересов ребенка осуществляется родителями (лицами, их заменяющими), а в случаях, предусмотренных данным Кодексом, органом опеки и попечительства, прокурором и судом (пункт 1); должностные лица организаций и иные граждане, которым станет известно об угрозе жизни или здоровью ребенка, о нарушении его прав и законных интересов, обязаны сообщить об этом в орган опеки и попечительства по месту

фактического нахождения ребенка; при получении таких сведений орган опеки и попечительства обязан принять необходимые меры по защите прав и законных интересов ребенка (пункт 3).

Оспариваемые нормы Семейного кодекса Республики Татарстан по своему содержанию и правовому смыслу аналогичны указанным положениям Семейного кодекса Российской Федерации и не устанавливают собственного правового регулирования, отличающегося от требований, закрепленных названными нормами федерального законодательства. Из этого следует, что проверка конституционности частей 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан фактически означала бы оценку указанных норм Семейного кодекса Российской Федерации на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

Относительно доводов заявительницы о несоответствии статьи 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» Конституции Республики Татарстан необходимо указать следующее.

Частью 1 статьи 8 Федерального закона от 24 апреля 2008 года № 48-ФЗ «Об опеке и попечительстве» определены полномочия органов опеки и попечительства, при этом частью 2 данной статьи установлено, что полномочия органов опеки и попечительства могут быть предусмотрены в том числе и законами субъектов Российской Федерации.

На основании указанных норм федерального законодательства, в целях защиты прав и законных интересов граждан статьей 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» установлены функции органов опеки и попечительства. При этом ни федеральным, ни республиканским законодательством функции по принудительному исполнению судебных актов к полномочиям органов опеки и попечительства не отнесены.

Непосредственное осуществление функций по принудительному исполнению судебных актов, актов других органов и должностных лиц в соответствии с частью 2 статьи 5 Федерального закона от 2 октября 2007 года № 229-ФЗ «Об исполнительном производстве» (в редакции Федерального закона от 5 апреля 2013 года № 49-ФЗ) возлагается на судебных приставов-исполнителей структурных подразделений Федеральной службы судебных приставов и судебных приставов-исполнителей структурных подразделений территориальных органов Федеральной службы судебных приставов.

Следовательно, статья 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции

Республики Татарстан. По смыслу пункта 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» основанием к рассмотрению дела является обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствуют ли Конституции Республики Татарстан обжалуемые заявителем нормы, отсутствие же такой неопределенности влечет отказ в принятии обращения к рассмотрению.

Кроме этого, требуя признать части 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан и статью 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан» не соответствующими Конституции Республики Татарстан, гражданка Т.Н. Рудницкая фактически ставит перед Конституционным судом Республики Татарстан вопрос о необходимости установления механизма взаимодействия органов опеки и попечительства и службы судебных приставов по вопросам исполнения судебных актов, вынесенных в отношении несовершеннолетних лиц, а также о наделении органов опеки и попечительства функциями по принудительному исполнению таких актов. Между тем разрешение поставленных заявительницей вопросов предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Т.Н. Рудницкой на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 2 и 6 статьи 47 Семейного кодекса Республики Татарстан и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 27 февраля 2004 года № 8-ЗРТ «Об организации деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Т.Н. Рудницкой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 3-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Гаилə кодексының 47 статьясындагы 2 һəм 6 өлешлəре һəм «Татарстан Республикасында опека һəм попечительлек органнары эшчəнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендəге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы белəн үзенең конституциячел хокуклары һəм иреклəре бозылуга карата гражданка Т.Н. Рудницкая шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
18 май
Казан шəһəре

# БИЛГЕЛƏМƏСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рəисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сəхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендə суд утырышында гражданка Т.Н. Рудницкаяның шикаятен алдан өйрəнгəн судья А.А. Хамматова бəялəмəсен тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы Гаилə кодексының 47 статьясындагы 2 һəм 6 өлешлəре һəм «Татарстан Республикасында опека һəм попечительлек органнары эшчəнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендəге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы белəн үзенең конституциячел хокуклары һəм иреклəре бозылуга карата гражданка Т.Н. Рудницкая шикаять белəн мөрəҗəгать итте.

Шикаятьтəн һəм аңа кушып бирелгəн документларның күчермəлəреннəн аңлашылганча, Казан шəһəре Яңа Савин район судының 2011 елның 17 октябрендəге карары белəн гражданка Т.Н. Рудницкаяның яшəү урыны буенча аңа балигъ булмаган оныгы белəн аралашу тəртибе билгелəнгəн. Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшлəре буенча суд коллегиясенең 2011 елның 14 ноябрендəге кассация билгелəмəсе белəн күрсəтелгəн карар үзгəрешсез калдырылган. Казан шəһəре Яңа Савин район судының 2014 елның 20 ноябрендəге билгелəмəсе белəн Казан шəһəре Яңа Савин район судының 2011 елның 17 октябрендəге карарын үтəү тəртибе һəм алымы үзгəртелгəн һəм əбисе — гражданка Т.Н. Рудницкая оныгы белəн бала яшəгəн фатирда аралашырга тиеш дип күрсəтелгəн.

Мөрəҗəгать итүче күрсəткəнчə, суд приставының-башкаручының баланың ата-анасына карата суд карарын билгелəнгəн тəртиптə үтəү турындагы талəплəре үтəлмилəр һəм мөрəҗəгать итүче үзенең балигъ булмаган оныгы белəн аралаша алмый. Шуңа бəйле рəвештə гражданка Т.Н. Рудницкая барлыкка килгəн вəзгыятьне хəл итүгə ярдəм итү турындагы гариза белəн төрле инстанциялəргə, шул исəптəн Казан шəһəренең Авиатөзелеш һəм Яңа Савин районнарының опека һəм попечительлек органнарына мөрəҗəгать иткəн. Лəкин, аның мөрəҗəгатьлəренə

алынган җаваплардан күренгәнчә, суд актларын мәҗбүри үтәтү функцияләрен гамәлгә ашыру законнар нигезендә аларның компетенциясенә керми.

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 47 статьясының дәгъва белдерелә торган нормалары белән түбәндәгеләр билгеләнә: баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау ата-аналар (аларны алмаштыручы затлар) тарафыннан, ә Россия Федерациясе Гаилә кодексында каралган очракларда опека һәм попечительлек органы, прокурор һәм суд тарафыннан гамәлгә ашырыла (2 өлеш); баланың гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч янау турында, аның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында мәгълүм булган оешмаларның урындагы затлары һәм башка гражданнар бу хакта баланың факттагы тору урыны буенча опека һәм попечительлек органына хәбәр итәргә тиеш; мондый белешмәләр алган опека һәм попечительлек органы баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча кирәкле чаралар күрергә тиеш (6 өлеш).

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелә торган 5 статьясы белән опека һәм попечительлек органнарының функцияләре билгеләнгән.

Гражданка Т.Н. Рудницкая, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр белән билгеләнгән җайга салу аның да, оныгының да законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга китерә, чөнки опека, попечительлек һәм суд приставлары хезмәте органнарының балигъ булмаган затларга карата чыгарылган суд актларының үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән килешенгән үзара эшчәнлегенең механизмын билгеләми, дип күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче шулай ук опека һәм попечительлек органнарының балигъ булмаган затларга карата чыгарылган суд актларын мәҗбүри үтәтүне гамәлгә ашыру функциясенең булмавын законсыз дип саный, чөнки, аның фикеренчә, күрсәтелгән орган, үзенең максатчан билгеләнешеннән чыгып, баланың ата-анасы тарафыннан суд карарын үтәтүгә ярдәм итәргә һәм Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 58 статьясында әбисенең оныгы белән аралашу хокукын күздә тота торган нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтергә тиеш.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 47 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләре һәм «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы аның конституциячел хокукларын боза дип күрсәтә һәм аларны Татарстан Республикасы Конституциясенең 38 (беренче, өченче һәм дүртенче өлешләр), 40 (беренче өлеш), 60 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Гаилә кодексының 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә гаилә законнары әлеге Кодекстан һәм аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнардан, шу-

лай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан тора, бу чакта Россия Федерациясе субъектлары законнарындагы гаилә хокукы нормалары күрсәтелгән Кодекска туры килергә тиеш.

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 56 статьясы нигезендә баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау ата-аналар (аларны алмаштыручы затлар) тарафыннан, ә әлеге Кодекста каралган очракларда опека һәм попечительлек органы, прокурор һәм суд тарафыннан гамәлгә ашырыла (1 пункт); баланың гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч янау турында, аның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында мәгълүм булган оешмаларның вазыйфаи затлары һәм башка гражданнар бу хакта баланың факттагы тору урыны буенча опека һәм попечительлек органына хәбәр итәргә тиеш; мондый белешмәләр алганда опека һәм попечительлек органы баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча кирәкле чаралар күрергә тиеш (3 пункт).

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының дәгъва белдерелә торган нормалары үзенең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча Россия Федерациясе Гаилә кодексының күрсәтелгән нигезләмәләренә охшаш һәм федераль законнарның югарыда аталган нормаларында беркетелгән таләпләрдән аерылып торучы үз хокукый җайга салуын билгеләми. Моннан аңлашылганча, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 47 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләрнең конституциячеллеген тикшерү Россия Федерациясе Гаилә кодексының күрсәтелгән нормаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, ә бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законындагы 5 статьяның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәү турындагы дәгъвасына карата түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк.

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше белән опека һәм попечительлек органнары вәкаләтләре билгеләнгән, монда әлеге статьяның 2 өлеше белән опека һәм попечительлек органнары вәкаләтләре шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары законнары белән дә каралырга мөмкин дип билгеләнгән.

Федераль законнарның күрсәтелгән нормалары нигезендә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы белән опека һәм попечительлек органнарының функцияләре билгеләнде. Монда федераль законнарда да, республика

законнарында да суд актларын мәҗбүри үтәтү опека һәм попечительлек органнары функцияләренә кертелми.

«Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның (2013 елның 5 апрелендәге 49-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 5 статьясындагы 2 өлеше нигезендә суд актларын, башка органнарның һәм вазыйфаи затларның актларын мәҗбүри үтәтү функцияләрен турыдан-туры гамәлгә ашыру Федераль суд приставлары хезмәте структур бүлекчәләренең суд приставлары-башкаручыларына һәм Федераль суд приставлары хезмәте структур бүлекчәләре территориаль органнарының суд приставлары-башкаручыларына йөкләнә.

Димәк, «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты мәгънәсе буенча мөрәҗәгать итүче шикаять биргән нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булып тора, мондый билгесезлекнең булмавы мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга китерә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 47 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләрен һәм «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны таләп итеп, гражданка Т.Н. Рудницкая фактта Татарстан Республикасы Конституция суды алдында опека һәм попечительлек органнары һәм суд приставлары хезмәтенең балигъ булмаган затларга карата чыгарылган суд актларын үтәтү мәсьәләләре буенча үзара эшләү механизмын билгеләү кирәклеге турындагы, шулай ук опека һәм попечительлек органнарына мондый актларны мәҗбүри үтәтү функцияләрен бирү турындагы мәсьәләне куя. Шул рәвешле, мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, ул исә закон чыгаручы компетенциясенә керә, Татарстан Республикасы Конституция суды вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче, икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 47 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләре һәм «Татарстан Республикасында опека һәм

попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.Н. Рудницкая шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Т.Н. Рудницкаяга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 3-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.А. Косуровой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания "Ветеран труда"»**

21 мая
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки А.А. Косуровой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан 25 марта 2015 года обратилась гражданка А.А. Косурова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания "Ветеран труда"». Согласно оспариваемой норме под ведомственными знаками отличия в труде в данном Законе понимаются награды, в том числе почетные грамоты, дипломы, нагрудные и почетные знаки, звания почетных и заслуженных работников отрасли (ведомства), учрежденные за заслуги и достижения в труде органами государственной власти и иными государственными органами СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральными органами общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующими (участвовавшими) в осуществлении государственных (ведомственных) функций; перечень указанных органов определяется в порядке и на условиях, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Как следует из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка А.А. Косурова обратилась в отдел социальной защиты в Советском районе Управления социальной защиты Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в муниципальном образовании города Казани с заявлением о присвоении ей звания «Ветеран труда», так как у нее имеется необходимый для этого трудовой стаж, а также награды — значки «Ударник-73» и ЦК ВЛКСМ «Молодой передовик производства». Однако заявительнице было отказано в присвоении указанного звания, поскольку Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодежи (далее — ВЛКСМ) являлся общественной организацией, не участвовавшей в осуществлении государственных (ведомственных) функций, и учрежденные им награды не могут служить основанием для присвоения звания «Ветеран труда».

Не согласившись с отказом, гражданка А.А. Косурова обратилась в Ново-Савиновский районный суд города Казани, который

решением от 25 декабря 2014 года, оставленным в силе апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан от 12 марта 2015 года, отказал ей в удовлетворении исковых требований о признании права на присвоение звания «Ветеран труда».

По мнению заявительницы, признание ВЛКСМ общественной организацией, не участвовавшей в осуществлении государственных (ведомственных) функций, не является правомерным. В качестве обоснования своей позиции гражданка А.А. Косурова ссылается на положения Устава ВЛКСМ, принятого XIV съездом ВЛКСМ, с изменениями, внесенными XV, XVII и XVIII съездами ВЛКСМ, согласно которым ВЛКСМ наряду с осуществлением иной деятельности участвует в управлении государственными и общественными делами, в решении политических, хозяйственных и социально-культурных вопросов, пользуется правом законодательной инициативы в лице своего общесоюзного и республиканских органов.

Заявительница также отмечает, что в Перечне ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденном приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481 «Об утверждении Перечня ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания “Ветеран труда” в Республике Татарстан», упоминаются нагрудные знаки и знаки отличия, которые ранее выдавались Центральным комитетом ВЛКСМ («Победитель социалистического соревнования ... года» Центрального Комитета КПСС, Совета Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ, а также «Ударник ... пятилетки» Центрального Комитета КПСС, Совета Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ).

В этой связи гражданка А.А. Косурова считает, что неопределенность в содержании оспариваемой нормы приводит к тому, что в одних случаях ВЛКСМ признается организацией, осуществлявшей государственные (ведомственные) функции, а в других случаях нет. Тем самым заявительница делает вывод, что реализация Закона Республики Татарстан ставится в зависимость от усмотрения конкретного правоприменителя, что не может служить условием единообразного применения обжалуемой нормы и в итоге влечет нарушение ее права на присвоение звания «Ветеран труда».

Кроме того, заявительница указывает, что согласно примечанию к Перечню ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, данный Перечень не является исчерпывающим и может быть дополнен в том числе и теми знаками отличия, которыми она была награждена.

На основании изложенного гражданка А.А. Косурова просит признать часть 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”» не соответствующей статьям 13, 28, 29 (часть первая), 54 (части первая и вторая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Оспариваемые заявительницей положения части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”» уже являлись предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан в связи с жалобой гражданки Ф.Я. Суфияровой. Согласно содержащейся в постановлении от 25 марта 2014 года № 58-П правовой позиции Конституционного суда Республики Татарстан установление в части 2 статьи 1 оспариваемого Закона Республики Татарстан условия об отнесении к ведомственным знакам отличия в труде наград центральных органов только тех общественных объединений и организаций, которые участвуют (участвовали) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, производно от публично-правовой природы отношений, связанных с присвоением звания «Ветеран труда», поскольку присвоение лицу данного звания влечет возникновение обязанности соответствующего государственного органа по предоставлению ветерану труда мер социальной поддержки, финансируемых за счет средств бюджета. Тем самым установленное республиканским законодателем условие отнесения наград центральных органов общественных объединений и организаций к числу ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых для присвоения звания «Ветеран труда», не может рассматриваться как нарушающее конституционный принцип равенства, поскольку данное условие основано на учете объективно существующих различий между общественными объединениями и организациями, вносящими (вносившими) свой вклад в осуществление государственных (ведомственных) функций, и теми из них, которые не участвуют (не участвовали) в данной деятельности. При этом Конституционный суд Республики Татарстан на основе анализа оспариваемой нормы и находящихся с ней в нормативном единстве положений иных нормативных правовых актов указал, что правомочие на участие в осуществлении общественными объединениями и организациями государственных (ведомственных) функций должно быть закреплено не только в уставах этих общественных объединений и организаций, но и в нормативных правовых актах, принятых органами государственной власти и определяющих статус соответствующих общественных объединений и организаций.

Таким образом, указанное постановление Конституционного суда Республики Татарстан и сформулированные в нем на основе конституционно-правового истолкования содержания и смысла оспариваемых норм правовые позиции сохраняют свою силу, что в соответствии с пунктом 3 части первой статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» является основанием для отказа в принятии к рассмотрению обращения по тому же предмету.

Кроме того, из материалов дела следует, что, требуя признать оспариваемую норму не соответствующей Конституции Республики Татарстан, заявительница фактически ставит вопрос об отнесении ВЛКСМ к числу общественных организаций, участвовавших в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых учитываются при

присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан. Однако порядок и условия отнесения государственных и иных органов к перечню органов, ведомственные знаки отличия в труде которых учитываются при присвоении звания «Ветеран труда», как и сам перечень указанных органов, регламентируются не обжалуемыми нормами Закона Республики Татарстан, а иными нормативными правовыми актами, которые в жалобе не оспариваются. Разрешение же поставленного гражданкой А.А. Косуровой вопроса о дополнении Перечня ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденного приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481, наградами ВЛКСМ, в частности имеющимися у заявительницы значками «Ударник-73» и ЦК ВЛКСМ «Молодой передовик производства», не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь пунктами 1 и 3 части первой статьи 46, частями первой и пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72 и 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.А. Косуровой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О Порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”», поскольку по предмету обращения Конституционным судом Республики Татарстан ранее было вынесено постановление, сохраняющее свою силу, а разрешение иных поставленных в ней вопросов неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.А. Косуровой и в Государственный Совет Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 4-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка А.А. Косурова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
21 май
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә суд утырышында гражданка А.А. Косурованың шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына 2015 елның 25 мартында «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка А.А. Косурова шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъва белдерелә торган норма нигезендә хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары дигәндә хезмәттәге казанышлар һәм ирешкән уңышлар өчен дәүләт хакимияте органнары һәм СССРның, РСФСРның, Россия Федерациясенең башка дәүләт органнары, СССР, РСФСР, Россия Федерациясе иҗтимагый берләшмәләренең һәм оешмаларының дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашучы (катнашкан) үзәк органнары тарафыннан гамәлгә куелган бүләкләр, шул исәптән мактау грамоталары, дипломнар, күкрәк һәм мактау тамгалары, тармак (ведомство) буенча мактаулы һәм атказанган хезмәткәрләре исемнәре дип аңлашыла; күрсәтелгән органнарның исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан урнаштырылган тәртиптә һәм шартларда билгеләнә.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка А.А. Косурова Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районындагы идарәсенең социаль яклау бүлегенә үзенә «Хезмәт ветераны» исемен бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итте, чөнки аның моның өчен кирәкле хезмәт стажы, шулай ук бүләкләре — «Ударник-73» һәм ВЛКСМ ҮК «Производствоның яшь алдынгысы» значоклары бар. Ләкин мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән исемне бирүдән баш тартылган, чөнки Яшьләрнең бөтенсоюз Ленин коммунистик берлеге (алга таба — ВЛКСМ) дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашмаган җәмәгать оешмасы булып тора һәм ул гамәлгә куйган бүләкләр «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен нигез булып тора алмый.

Баш тарту белән килешмичә, гражданка А.А. Косурова Казан шәһәре Яңа Савин район судына мөрәҗәгать итә, ул исә Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең 2015 елның 12 мартындагы апелляция билгеләмәсе белән үз көчендә калган 2014 елның 25 декабрендәге карары белән мөрәҗәгать итүчегә «Хезмәт ветераны» исемен бирү хокукын тану турында дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарта.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, ВЛКСМны дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашмаган җәмәгать оешмасы дип тану законсыз. Үз позициясен нигезләү буларак, гражданка А.А. Косурова ВЛКСМның XIV съездында кабул ителгән һәм XV, XVII һәм XVIII съездларында үзгәрешләр кертелгән ВЛКСМ Уставы нигезләмәләренә таяна, алар нигезендә ВЛКСМ башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру белән бергә дәүләт һәм җәмәгать эшләре белән идарә итүдә, сәяси, хуҗалык һәм социаль-мәдәни мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша, үзенең гомумсоюз һәм республика органнары исеменнән закон чыгару инициативасы хокукыннан файдалана.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук «Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 29 июнендәге 481 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегендә элек ВЛКСМ Үзәк комитеты тарафыннан бирелгән күкрәк тамгалары һәм аерымлык тамгалары (КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКының «...елгы социалистик ярыш җиңүчесе», шулай ук КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКының «... бишьеллык ударнигы») искә алына.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка А.А. Косурова дәгъва белдерелә торган норма эчтәлегендәге билгесезлек бер очракта ВЛКСМны дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашкан оешма буларак тануга, икенче очрак танымауга китерә дип саный. Шул рәвешле мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру конкрет хокук кулланучы ихтыярына бәйле итеп куела, бу исә шикаять бирелә торган норманы бер төрле куллану шарты булып тора алмый һәм, нәтиҗәдә, аның «Хезмәт ветераны» исемен бирү хокукын бозуга китерә.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегенә искәрмә нигезендә әлеге Исемлек тулы түгел һәм аңа өстәмәләр, шул исәптән мөрәҗәгать итүче бүләкләнгән аерымлык тамгалары да кертелергә мөмкин.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка А.А. Косурова «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешен Татарстан Республика-

сы Конституциясенең 13, 28, 29 (беренче өлеш), 54 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре гражданка Ф.Я. Суфиярова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торган иде. 2014 елның 25 мартындагы 58-П номерлы карардагы Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позициясе нигезендә дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешендә хезмәттәге ведомство аерымлык тамгаларына дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашучы (катнашкан) иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның үзәк органнары бүләкләрен генә кертү турындагы шартны билгеләү «Хезмәт ветераны» исеме бирелүгә бәйле мөнәсәбәтләрнең гавами-хокукый табигатеннән килеп чыга, чөнки затка бу исемне бирү тиешле дәүләт органының ветеранга бюджет акчалары исәбеннән финанслана торган социаль ярдәм чараларын күрсәтү йөкләмәсен барлыкка китерә. Шулай итеп, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның үзәк органнары бүләкләрен «Хезмәт ветераны» исеме бирү өчен исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кертүнең республика закон чыгаручысы тарафыннан билгеләнгән шарты, конституциячел тигезлек принцибын боза дип карала алмый, чөнки бу шарт дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда үз өлешен кертүче (керткән) иҗтимагый берләшмәләр белән оешмалар һәм әлеге эшчәнлектә катнашмаучы (катнашмаган) иҗтимагый берләшмәләр белән оешмалар арасында булган объектив аермаларны исәпкә алуга нигезләнә. Монда Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган норманы һәм башка норматив хокукый актларның алар белән норматив бердәмлектә булган нигезләмәләрне анализлау нигезендә иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашу хокукы әлеге иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар уставларында гына түгел, дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән һәм тиешле иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның статусын билгели торган норматив хокукый актларда да беркетелергә тиеш дип күрсәтте.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карары һәм анда дәгъва белдерелә торган нормаларның эчтәлеген һәм мәгънәсен конституциячел-хокукый аңлату нигезендә формалаштырылган хокукый позицияләр үз көчендә кала, ә бу исә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты нигезендә бер үк мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьне карауга кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Моннан тыш, эш материалларыннан аңлашылганча, дәгъва белдерелә торган норманы Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны таләп итеп, мөрәҗәгать итүче

фактта ВЛКСМны дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашкан, хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган җәмәгать оешмалары исәбенә кертү турындагы мәсьәләне куя. Ләкин дәүләт органнарын һәм башка органнарны хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган органнар исемлегенә кертү тәртибе һәм шартлары, күрсәтелгән органнарның исемлеге кебек үк, Татарстан Республикасы законының шикаять бирелә торган нормалары белән түгел, ә шикаятьтә дәгъва белдерелми торган башка норматив хокукый актлар белән регламентлана. Гражданка А.А. Косурова тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 29 июнендәге 481 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегенә ВЛКСМ бүләкләрен, аерым алганда, мөрәҗәгать итүчедә булган «Ударник-73» һәм ВЛКСМ ҮК «Производствоның яшь алдынгысы» значокларын өстәү турындагы мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 3 пунктларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче өлешләренә, 69, 72 һәм 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка А.А. Косурова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка А.А. Косуровага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 4-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды